

МАРСЕЛЬ
# ГАЛИЕВ

# УЧЫМДА –
# ТУРГАЙ ШӘҮЛӘСЕ

**Шигырьләр**

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2008

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Г18

**Галиев М.Б.**

Г18 Учымда — тургай шәүләсе: шигырьләр / Марсель Галиев. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. — 208 б. — 2000 д. — ISBN 978-5-298-01640-7

Язучы, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Марсель Галиевнең бу китабына, нигездә, соңгы елларда иҗат ителгән шигырьләре туплап бирелде.

ISBN 978-5-298-01640-7

© Татарстан китап нәшрияты, 2008
© Галиев М.Б., 2008

## ТУГАН ТЕЛ ШИФАСЫ

Артта калган еллар...

Көле суынган учак урыннары. Кәгазе саргайган шигырь юллары. Күңел тугайлары гына элеккечә. Анда һаман шулай: малайчак мәтәлчек ата, җил белән узыша, мәмрәп пешкән җиләк салынган кыңгырау чәчәк касәсен тел өстенә озата; хуш исле тәменнән рәхәт кырачлап, күзләрен йома. Болыннарда колыннар белән узыша торгач, ул, үзе дә сизмичә, малайчактан үсмерчакка сикерә. Айдан карап торган Зөһрә кызны көнләштермәс өчен, капка баганасының күләгәле ягына ышыкланган егет, кыз каршында кыюсызлык газабын үтеп, тәүге тапкыр үбешү ләззәте кичерә.

Аннары... (иң истә калганы) төнге сентябрь күгенә карап, баскан җиреңне оныту, төн караңгылыгында коенып, галәми чиксезлек белән бермәбер калу халәте. Шыгрым тулы йолдыз арасыннан саркып тамган хикмәти сүзләр... Күңелдән кәгазьгә күчкән чакта, асылы җуелып, хәрабәле кайтавазы гына калган сүзләр... Аннары... ачудан ертып ташланган кәгазь гаеплемени каләмең көчсезлегенә?! Сындырып ташланган каләмең гаеплемени күңелең сайлыгына?!

Тел дәрьясы дәшми. Ул көтә, сабырлыгын һәр сүз кальбенә тигез таратып, синең колач салып йөзәргә өйрәнүеңне көтә...

* * *

Җир-Су-Кояш тылсымыннан бар ителеп, илаһи камиллеккә ирешкән гөлләр нинди телдә сөйләшә икән?

Сүзләргә әверелмәгән тойгылар телендәме?

Галәми тибрәнешкә көйләнгән дулкын телендәме?

Без ишетә алмаган аһәңнәр телендәме?

Тереклеккә үсү дәрте, күктәге яктылык шәменә омтылыш бирелгән икән, димәк, һәммә нәрсәнең дә канатлы җаны, уйлы күңеле бар.

Шигъри сүз исә күңел күгенең җиденче катында кабынадыр кебек. Кабына да... Утка сикергән күбәләк шикелле, нәни кисәүгә әверелеп, ак кәгазь аланына төшеп күмерләнә. Шул күмерләрдән пышылдап янган шигырь учагы хасил була.

Ана теленең бибәһа мирасыннан мин күпме сүзне чумырып алырга сәләтле? Белмим. Гаҗизләнмә, хәзинәңдәге сүзләр санын барыбер белә алмаячаксың дип, күктән Раббыбыз мут елмаеп күзәтәдер шикелле...

Җир йөзендәге иң борынгы халык — төрки бабаларыбыз — меңнәрчә еллар буена күпме сүз тудырган, чарлаган, шомарткан, көмешен — көмешкә, мәрҗәнен — мәрҗәнгә, бакырын бакырга аерып куйган.

Сүзләр мириадасы... Хәтер ятьмәсенә эләккән кайбер асылташтай сүзләрне үзалдыма кабат-кабат әйтеп карыйм: борынгы заманнар кайтавазы яңгырап ишетелә. Иң кадими, беренче сүз-атамалар, бәлки, су һәм утка бирелгәндер. Тереклекне бар итүче дә, давылланып, гарасатка әверелсә, юк итә алучы кодрәт тә бит ул су һәм ут стихиясе.

Ана карынында сулы сүрү эчендә яралган һәм бөтен гомере буена бер генә көн дә сусыз тора алмаган адәми затка иң кирәкле сүз нинди кыска, үтемле яңгыраш алган — су!

Тел өстеннән тәгәрәп төшкән һәр сүзнең тамыры күңел тирәнлекләренә юл ярып, мәңгегә береккән. Су диюгә, минем хәтерем уяна; үз гомеремдә күргән, тәмен татыган, каршына тезләнгән күпме чишмәләрне, хозурланып су коенган елга-

күлләрне, диңгез киңлекләрен аң-зиһенем аша үткәрәм. Малай чакта, өлкән апаларга ияреп, ерак урманга җиләк җыярга баргач, су эчәсем килеп тәмам кибеккәч, арба эзенә ятып, өслеген гөнаһсыз вак чебеннәр кытыклап торган җылымса болганчык суны эчкәнемне, кайту сукмагында тау астыннан ургылып чыккан чишмәгә юлыккач инде, мәңге туймас кебек, теш камаштыргыч чишмә суын йотлыгып-йотлыгып уртлаганымны искә төшерәм.

Гаҗәп бит, су дип әйткән шушы кыска мизгелнең меңнән бер өлешендә күпме хатирә күңелне сызып уза. Русның «вода», инглизнең «water» дигән сүзләре миндә бернинди тойгы да уятмый. Чөнки бу сүзләр минем туган телемнән яралмаган, тән күзәнәкләремне, аң-зиһенемне балачагымнан сугарып килмәгән.

Ана телебезнең бөеклегенә хәйраннар калам. Табигатькә яшәү көче биргән терек суны әнә нинди кыска-үтемле сүз белән атаган бит! Күз алдыма килә: яраланган яугир эссе кояш астында кибегеп, соңгы көчен җыеп, шуыша-шуыша үз станына килеп җитә, чатнаган иреннәре арасыннан бары бер сүз, соңгы сүзен сыгып чыгара. Су — бер сулышлык сүз. «С» — көмеш аваз, чыңлап ачылып китә. «У» — еракка яңгырап китәрлек йөгерек аваз. Шушы ике аваз, тәңгәл килеп, халәтенә карап: йә куаныч, йә ялвару, йә шатлыклы хәбәр, йә сагаю, йә дәһшәт булып яңгырарга мөмкин.

Менә мин ата-бабаларыбыздан мирас булып килгән тел хәзинәсеннән фәкать бер сүзне мисалга алып, учымда биетеп карадым.

Артта калган еллар, дим... Хәзер инде мин кирәкле сүзне таба алмау гаҗизлегеннән каләмемне сындырып ташламыйм. Кәгазьне дә рәнҗетмим. Ак кәгазь минем өчен ак намазлык кебек.

Әйе, еллар боҗрасы салынган тәҗрибәм бар. Ялыннан эләктереп алып, иң чыгымчы сүзләрнең

дә тоягын уйнаттыра алам. Әмма тел дәрьясы каршында һаман да көчсезмен. Мин беләм! дип масая күрмә, белмәвең чабуыңнан тартыр — бу һәммәбезгә карый торган хакыйкать. Тел каршында без барыбыз да гомер буе көндәм өйрәнчек булып калабыз. Өйрәнергә омтылу дәрте хыялга канатлар куя. Бу — соңгы сулышыңа кадәр озата барачак иҗади яшәү чыганагы.

Үзем өчен мин шундый бер ачыш ясадым: ана теленең шифасы хакында бәгырьгә төшеп уйлану иде бу.

Була бит шундый сәгатьләр: берьялгызың каңгырып йөрисең. Күңелеңдә хис-тойгылар кабара бара, түгелер идең, янәшәңдә кем дә юк. Бермәлне кальбеңне тынычсызлап тулышкан тойгылар, сүзләргә әверелеп, «ишек-тәрәзәләреңне» тәкатьсез кага башлый. Син, түземеңне җуеп, сизмичә дә үз-үзең белән сөйләшә башлыйсың, йә үсемлекләргә, йә бөҗәкләргә эндәшәсең. Гомумән, үз телеңдә сөйләшү-аралашу яисә югары кимәлдә язылган сәнгатьле әсәр уку мәлендә сүз сәйләннәре тән күзәнәкләреңне иркәләп бер көйгә агыла, һәр сүзнең эчке моңы җаныңа сихәтлек иңдерә башлый. Син, сүзләр тибрәнеше аша галәми ритмга көйләнеп, җан тынычлыгы аласың.

Туган тел шифасы... Туган тел дәвасы... Туган тел сихәте — бу гаҗәеп сер, әлегә өйрәнелмәгән могҗиза...

Җир йөзендә никадәр халык, никадәр тел бар? Хәер, моның санын төгәл белү бу очракта мөһим түгелдер. Ана теле шул телдә сөйләшүче милләт кешесенең йөз-кыяфәтендәге мимиканы, күз карашын, тавыш үзенчәлеген, җыр-моңын билгели. Мин, кая гына барсам да, үз милләттәшләремне елдам-кайнар күз карашыннан, тавыш тембрыннан танып алам. Ялгышам икән, димәк, ул кешенең нәсел ага-

чының кайсыдыр буынына татар каны кергән, тик ул аны үзе генә белми...

Ана телен онытып, бүтән телне үз иткән, чит халыклар арасында тамыр җибәргән милләттәшләремне дә очратканым бар. Шунысы гаҗәп: андыйларның сүз тәме, мәне башка, күзләрендә фәкать татар өммәтенә генә хас мут кайнарлык, ялкыны кабынырга торган күмер җетелеге сүнгән була. Әйе, ана сөте белән кергән сүзләр тәлгәше, бөтен вөҗүдеңә таралып, гомер буе тәнне, җанны сугарып тора икән шул. Туган телеңнән өзеләсең икән, эчтән дәрт биреп торган аһәң сүнә дә бүтән, ят тел хасиятенә күчкәндә җан тибеше табигый яшәү көеннән мәхрүм ителә. Адәми затның тәне, төскыяфәте, күз карашы, рухы үзгәрә башлый. Мондый чакта әнкә теленең көй шифасын, яңгыраш тылсымын сагынып җан сыктый, җан бәргәләнә, җан рәнҗи, рух шиңә... Ят тел әсирлегенә төшеп яшәргә хөкем ителү, җан асрау омтылышы гына өстенлек ала.

Ана теленә хыянәт иттеңме — димәк, син кылган гөнаһ яки изге гамәлләреңне иңеңдә язып баручы фәрештәләрне рәнҗетәсең.

Ана теленә хыянәт иттеңме — иң кадерле сүзләр әйтеп үткән буыннар хәтерен юата алудан мәхрүм каласың, нәсел чылбырың өзелә.

Ана теленә хыянәт иттеңме — табаныңны сыйпаган җир, башыңны сыйпаган күк белән үз телең аша береккән бәйләнешне җуясың; шулай итеп, язмыш китабыңны ачканда — бер телдә, япканда икенче телгә күчерелүен Гарештә кичермәсләр, син Күк каргышына дучар булачаксың...

Туган тел шифасы...

Моны тою бәхете бирелгән икән, шөкрана кылыйк.

Сүз сихәте, сүз дәвасы — уятучысын көтеп, күпме шигырь юлларына салынган хикмәтле дога.

Шигырь ул — күңел кылларыннан Раббы сулышына көйләнеп үрелгән аһәңле читлек. Шул читлеккә канатка-канат килгән сүзләр кәрваны савылып керә дә... тынга-тын, ымга-ым, моңга-моң килеп, куначага тезелә.

Дәшә белеп дәшкән тылсымыңнан кыйбла якка ачылсын да читлек, с ү з л ә р, үз иреген тоеп, күңел күгеңә сибелсеннәр! Адашып калырлар, таралышып югалырлар дип курыкма син, сүз-кошлар, канаты белән сыйпап тойгыларыңны уятканнан соң, кабат үз читлегенә кайтып, үз биеклегенә кунакларлар.

Шагыйрь бикләгән читлек ачкычы синең үз йөрәгеңдә...

*Марсель Галиев*
*2007*

*Каләм очында — галәм.*

*Ман каләмең галәм коесына,*
*Куләгәсез Куңел Ияләре*
*Суз кауриенда коенсыннар!*

*Каләм очында — галәм...*





## ТУГАН ТЕЛ

Бөек тә син, боек та син,
И туган тел, туган тел,
Күп гамәлләр кылган тел!
Аргамаклар җилеп чапкан,
Былбыл сайрап кунган тел.

Елатасың, юатасың,
И туган тел, туган тел,
Кәүсәр сулар юган тел!
Әткәм нигез ташы куйган,
Әнкәм бишек корган тел.

Уйлатасың, уятасың,
И туган тел, туган тел,
Дәрья булып тулган тел!
Шанлы, данлы дәверләрнең
Хөкемдары булган тел.

Талымлы син, ягымлы син,
И туган тел, туган тел,
Халкым кебек уңган тел!
Күктән иңгән иман нурын
Мәңге саклый торган тел!

*2004*

## ИЛҺАМ

Мин бер колың бары... Чабан гына,
Сүз артыннан әрсез чабам гына.
Узыштырам,
Сугыштырам,
Ирештерәм,
Сөзештерәм,
Килештерәм,
Үбештерәм.

Табуннарда елкы сүз — Атларым,
Табырлана елгыр тулпарларым.
Солтан сүзләр
күпме,
Олтан сүзләр,
Субай сүзләр
күпме,
Сукбай сүзләр,
Ялган сүзләр
күпме,
Янган сүзләр,
Канлы сүзләр
күпме,
Данлы сүзләр!

Дөнья карынында күпме серләр,
Күңел аранында күпме сүзләр,
Сез әзерме минем әмеремә?!
(Мин бу мәлдә тиңдер әмиреңә.)

Иңерәеп, ярсу чыбыркымны
Бер шартлатсам әгәр, кыланып;
Үрә баскан сүзләр табырында
Шомырайта барсы колагын.

Шул мәлеңдә дәррәү куба сафлар,
Кайный, уба сүзләр ташкыны.
Тупырдаган тояк тетрәвеннән
Күкрәп тибә йөрәк, ашкынып.

Бу бит сине күмеп китә торган
Гадел ташкын, изге гарасат.
Шушы ганимәттән тапталып бер
Көчсез калу бәхет ләбаса.

Туган телем минем — тиңсез диңгез,
Аргы яры — Ходай катында.
Мәдәт бир син, маяклары аның
Татар атлы дәрьял халкымда.

*2003*

## ЫШАНАМ

Мин ышанам сиңа, Күкләр Шаһы,
Барлыгыңа ихлас ышанам.
Бу ышаныч керми миңа читтән,
Мулла-мунтагайдан, ишаннан.

Бу ышану иңдерелгән миңа
Асмани-Күк дөньяларыннан.
Һәр тереклек иясенә күктән
Нинди олуг мәдәт салынган.

Галәми моң дулкынында рәхәт
Сулгып әйләнәдер һәр җисем.
Камил сайланышка дучар итеп,
Алган Раббы иң һиммәтлесен.

Нинди кодрәт, нинди илһам нуры!
Бар тереклек илаһ могҗиза.
Акыл көчсез калып сәҗдә кыла,
Бөек сәнгать өчен җан фида.

Уйлый беләә, уйный белә Җиһан,
Актарыла вакыт-дәрьялар.
Йолдыз белән йолдыз бәрелешеп,
Хасил була яңа дөньялар.

Шул гарасат, чиксез мәңгелектә
Без мосафир булып йөзгәнбез.
Уттан-судан яратылган җаннар
Күкнең җиде катын күргәнбез.

Киек Каз Юлыннан бу җиргә без
Сыналырга төшкән юлчылар.
Кем төшенми, шул төшемле яши,
Гөнаһларга күпме Җир чыдар?

Гаҗизләмим, Каһһар, сорау биреп,
Тәкъдир йолдызларың — күгеңдә.
Син хәрәкәт биргән хәятларның
Җан тибеше чиксез кальбеңдә.

Кичер мине, бер горурлык белән
Аваз салсам:
                Без бар! Без әле!.. —
Бер кәррәлек зәррә булган Җирнең
Инсан дигән гамьле бизәге.

Мин ышанам сиңа, Күкләр Шаһы!
Яшәү җирдә — илаһи дәвам.
Кальбеңдә бер тере күзәнәк мин,
Сәмави сүз иңгән үз догам.

*2005*

## ГАЛӘМИ УЙ

Сискәнә Җир. Каш җыера Күкләр,
Болыт белән болыт сөзешә.
Күк күкрәтеп, яшен ташын чөеп,
Җиһан белән Җиһан көлешә.

Бу көлүдә — бөек дәһшәт чыңы,
Ала өнен, адәм акылын.
Кемгә язган күрү бу дөньяның
Әүвәлендә туган ахырын?..

Күкрәп-яшьнәп Күкләр аңлашканда,
Куян кебек поса Җир җаны.
Ул бит бу галәмнең кеше дигән
Бөҗәк сарган нәни тузаны.

Әй! Тузан дип кимсетмәек әле,
Җир — галәмнең уйлы бөртеге!
Ике ярымшары тигез бизмән —
Һәр көне дә аның, һәр төне.

Күпме җаннар шытып шушы Җирдән
Күк гөмбәзен иңләп очкандыр;
Галәм дигән акыл дәрьясында
Үз дулкынын табып кочкандыр.

Көн белән төн. Аллаһ белән Иблис —
Ак кодрәт һәм Кара каһәрлек...
Илаһи көч ягы җиңалмаса,
Тормыш булыр тоташ каберлек.

Җир әлегә хәлле... Явызлыкның
Авызлыгын тота каерып.
Эчтә типкән утлы йөрәгеннән
Җан җылысын бирә аерып.

Берчак арыр... Күчәреннән күчәр,
Кеше мәкереннән өзлегер.
Бик тирәндә әрнеп сүнсә җаны,
Тораташка калыр өслеге.

...Менә үтте күкрәү-яшеннәре,
Юашланды күкләр яктырып;
Алтын таҗы булып Кояш чыкты,
Ярсу болытлардан котылып.

Хәтәр уйлар коллыгыннан мин дә
Ыргытылдым якты аланга.
Җир җылысы... Шөкерана кылам,
Тез чүктерер төсләр булганга.

Гөлгә кунган бал кортына карыйм,
Исем китеп карыйм, кызыгып.
Тездән батып чәчәк серкәсенә
Эшли, бахыр, «җиңен сызганып».

Тезләнеп бер гадел ачыш яса
Шушы нәни бөҗәк аркылы;
Ул бит Җирнең асыл бер үрнәге —
Чага торган баллы акылы.

*2006*

## ХӘЯТ

Төн. Таулар. Сирпелеп исәдер
Галәми җилләр генә.
Олыгаеп, сүзләр егыла
Шагыйрьнең йөрәгенә.

Төн. Дәрья. Ярларга үрелә
Адашкан дулкын гына.
Картайган йолдызлар егыла
Күк-галәм упкынына.

Ничекләр ышаныйм дөньяга
Шом-афәт киләсенә.
Сабырлык догасы кылыйммы
Бу кодрәт Иясенә...

*2004*

## УТЛЫ ДӘРТ

Төнге гөмбәз — түм-түгәрәк тирмә,
Уртасында балкый Җир шары.
Шул шарның бер нәни ноктасында
Үрсәләнә тормыш учагы.

Әле дөрли ярсу айгыр булып,
Аягүрә басып талпына.
Күмеренә кысып бар сулышын,
Җилгә сусап әле бер тына.

Күкнең текә гөмбәзеннән кинәт
Таеп китә йолдыз, атыла.
Учагыннан ыргып чыккан ялкын
Шул йолдызга таба тартыла.

Кушылалар... Утлы йомгак булып,
Шартлап куя учак — мең очкын!
Чая йолдыз шушы мәлдә җуя
Галәми дәрт кергән очышын.

Юктан — барга, бардан юкка чыгу
Серен Тәңре белә, билгеле.
Күк-ата һәм Җир-ананың бу бит
Күз кысышкан илаһ мизгеле.

*2006*

## УЯНУ ҮКЕНДЕРМӘГӘН ТӨШ

Югалтулар күпме булса,
Шуның кадәрдер табыш.
Артта калды борылышлар,
Алда көтә тукталыш.

Тукталышта төшәсе бар...
Ни хәбәр бар гарештән?
Каш җыерып каршы ала
Уң һәм сул як фәрештәң.

Икесе бер якка тарта,
Гөнаһ зурмы, савапмы?
Тәмуг, оҗмах ачкычына
Болар, ахры, җаваплы.

— Иңгә куныш, күпме еллар
Мине сынап йөрдегез?
Тыйнак мәхлук кына булсам,
Эшсез кала идегез.
Оҗмах ишеге ачкычын
Бирәме бирәрегез?

— Оҗмах ул — кадерен белеп
Җирдә яшәү, кинәнеп.
Монда — тәмуг, утлы кисәү
Өлешеңә тигәне!

Сират күперен чыкканны
Баш җәллад көтеп тора,
Имәнгеч карашы белән
Елмаеп-өтеп тора.

— Оҗмахтан тәмуг ясарга
Кызыга җирдә адәм.
Андыйларга Җир әрәм!
Тукта, тукта, нишләп әле
Синең кулыңда каләм?

Сезнең кавем үзен-үзе
Тиңлиме пәйгамбәргә,
Мондый чамасыз гөнаһы
Тигән тагын кемнәргә?!
Кем кушты сәләтсезләргә
Сүз җанын җәберләргә;
Ходай түгел, бодай өчен
Ак кәгазьне керләргә;
Гөрзиемнең иң саллысы
Медальле шагыйрьләргә!

Кайда күрдем соң мин моны?
Җәлладның йөзе таныш…
Әй, тукталыш, тукталыш!
Бусында мин төшмим әле,
Алгарак китеп барыш…

*2006*

## ИКЕ КҮК АРАСЫНДА

Без Җир дибез.
Тамырларга — Күк.
Безне чолгаган зәңгәрлек
Тамырларга — каберлек.
Кеше өчен — икесе дә — Күк.

*1971*

## СЕР АЧКЫЧЫ

Калдырганмы алгы көннәренә,
Бар серләрен Җирем чишмәгән.
Диңгезләрнең ярсу дулкыннары
Башлана бит тыйнак чишмәдән.

Кичәбезме язмыш сынауларын,
Урман-сулар — күңел дәвасы.
Суларның да, кире кайта-кайта,
Туган җиргә килә явасы.

Нинди тарту көче — бу бөек сер,
Моңа кадәр булган, булачак.
Игә кереп күпме гаҗизләнмә,
Булачактан дәвам калачак.

Гадәләтле яшәү өчен җирдә
Бирелгәнме һәммә мөмкинлек?
Гарьсез яшәү — гамең булсын дисәң,
Тәүдә үзең кыл син игелек.

Дөнья серләренә ярау ачкыч
Шуннан табыладыр иң элек.

*2005*

## ЯШӘҮ ФӘНЕ

Бу тормышта яшәү фәнен
Тора-тора өйрәнәсең.

Егет чакта, көязләнеп,
Кара мыек җибәрәсең.

Йом күзеңне, дөнья бу! дип,
Бер чибәргә өйләнәсең.

Вак туралган чәкчәк бәхет
Килә тора — кинәнәсең.

Бардан — юкка, юктан барга
Әкеренләп көйләнәсең.

Дөнья куу кәсебенә
Комарланып иярәсең.

Тамак ялын мең кайгыртып
Миләнәсең, чиләнәсең.

Тук бөртекләр калмасмы дип,
Гомереңне җилгәрәсең.

Бу тормыштан туйдым ла дип,
Үзалдыңа сөйләнәсең.

Ә беркөнне... кабыгыңны
Салып, күккә юнәләсең.

Исәпле Җир шәрә җанга
Тоттырмый шул иганәсен.

Күктә тәмуг газабына
Иярәнеп көйләнәсең.

Кайчагында, кызып китеп,
Җәлладларга кизәнәсең.

Гөнаһ кылмый яшәү фәнен
Яңабаштан өйрәнәсең.

Күк катыннан Җиргә карап,
Үзалдыңа сөйләнәсең:
— Их, тагын бер кабатларга
Шул ук тормыш әйләнәсен!..

*2005*

## ВАКЫТ-АКУЛА

Уй дәрьясы ярларыннан
Күккә багып, ятьмә кора
Күпме акыл иясе.

Тик көнендә билгеләнми
Алтын маймыч бәясе…

## ДӨНЬЯ КАРШЫНДА

Дөньяга карап, йөземне
Чыттым да, чытмадым да;
Сират күперләре аша
Чыктым да, чыкмадым да.

Өлешкә тияр көмешләр
Тиде дә, тимәде дә;
Ятларга каласы ярлар
Сөйде дә, сөймәде дә.

Койрык чәнчеп чабар бәхет
Килде дә, килмәде дә;
Кырыс еллар горур башны
Иде дә, имәде дә.

Елгыр җаннар ятьмәсенә
Каптым да, капмадым да;
Тел-дәрьяда Сүз хикмәтен
Таптым да, тапмадым да.

Бу җирдә яшәү кадерен
Сиздем дә, сизмәдем дә;
Дөньялыкның биш кыйтгасын
Гиздем дә, гизмәдем дә.

Әйтерләр: гомер челтәрен
Үрде дә, үрмәде дә;
Яшәүнең тәмен бозмыйча
Үлде дә... үлмәде дә!..

*2004*

## ВАКЫТ-АТА ЧЕРЕМ ИТӘ

Нәни Вакыт сәгать телен
Уңга-сулга чиртеп уйный.
Күке чыга оясыннан.

Өлкән Вакыт
арган инде,
Пирамидалар кубарып
Мәңгелекләр кыясыннан.

## ТЕЛӘКЛЕ ТЕРӘК

Күктән йолдыз тамар мәл бу,
Тел коесы сиртмәсенә
Сайрар сандугач кунса...

Мин бәхетле, дияр Шагыйрь,
Туган телгә сан булса.

*Гасыр китабын актарсаң,
Кан тәме дә көл тәме.
Дөньяны без көтәбезме,
Дөнья безне көтәме?!*





## ТУЗАН БУЛЫП

Көбә күлмәк. Булат кылыч. Иярле ат.
Мин шул дәвер тоягыннан
Сыктап калган туфрактан;

Тузан булып, гөлдән гөлгә
Куны киләм ерактан.



## Ә ШУЛАЙ ДА

Борынгыча — Рим исән!
Һуннар башы Аттиланың
Бүгенгегә бүләге.

Җимермичә калган өчен
Даны белән түләде...

## ТАШЛАР ДӘШМИ

Вакыт ләм-мим. Сорап кара:
Кем корган? Кем төзүче?
Батыр кала җимерүче.

Хәрабәдән ташлар җыя
Көнлекче, көн итүче.

## УТ КҮЛМӘГЕ

Кайда гына биесә дә
Керләнми шул
Өрфия ут күлмәге.

Ут кагынган җирдә кала
Кара күмер көлләре.



## ДАЛА ДОГАСЫ

Кылыч йөзе кебек үткен –
Бу кыпчак даласымы?
Бәйсез-уйнак җилне тешләп
Атларда чабасымы?

Әлегәчә таланмаган
Курганнар табасымы?

Учагы сүнгән дәвернең
Көлләрен кагасымы?

Миндә дала каны бар дип,
Шушында каласымы?
Балбал шәүләсенә ятып
Бер сыктап аласымы?

Беләмме дала догасын,
Мин дала баласымы?..

## ТӨШТӘ АБЫНУ

Бату ханның ат тоягы
Тиеп киткән чуерташ,
Сөйлә миңа таш телендә:
Заманнарга уендаш
Акыл миндә, гасырларны
Чуерташ итеп чөям!
Кылыч кисмәгән башымны
Синең каршыңда иям.

Соңлап килгән каһарманлык...
Кичер мине, и Ходам.
Төшемдә ташка абынып,
Уяндым мин йокыдан.

## ЭЗЛӘМӘГЕЗ

Каһәрле шул кадере…
Галәмгә күмелгән Җир шары —
Чыңгыз ханның кабере.

## ҖИҺАНГИР

«...Кайсы да булса корольне әйбәт диләр икән, димәк, аның хакимияте барып чыкмаган.»
«Сарык баш булган арыслан чирүенә караганда арыслан баш булган сарыклар чирүе көчлерәк.»
«Мин Чыңгыз хан кебек бәхетле була алмадым.»

*Н.Бонапарт*

Тәңре улы санап үзен
Фатиха алгач Күктән,
Кытай диварлары аның
Кодрәтеннән тез чүккән.

Әмер генә бирсен юкса
Чыңгыз атлы бөек хан, —
Күпме халык чирүләре
Бер исемгә оешкан.

Елгаларның юлын борып,
Тау-кыялар күчереп,
Колачлаган кыйтгаларны,
Илләрне ду китереп.

Алтын өзәңгегә баскан
Дәвер — аның дәвере!
Илгә ия ияр менсә,
Гаярь ирләр яу йөрер.

Көчле кавем шулай гына
Раслый ала исемен;
Кимсенмәслек булып иңсен
Исемеңә җисемең.

Менә тагын ук очына
Хәтәр хәбәр куелды;
Тик нигә соң тынып калган
Шаулы дала куены? —
Байраклар да җилфердәми,
Гаскәр дә тын бу юлы...

Баба ханнар дәвереннән
Килгән бакый ул гадәт:
Яу-сәфәргә кузгалганда,
Кылу өч көн гыйбадәт.

Берьялгызы! Ак тирмәдә,
Учак янәшәсендә,
Тезләнеп Хан сәҗдә кыла
(Җитмеш ике яшендә)...

Дала догасын пышылдап,
Ул инәлеп ялвара.
Чәч учмасы, ут капкандай,
Көлсуланып агара.

Инде менә ике тәүлек
Тып-тын гаскәр диңгезе;
Күк гөмбәзен терәп тора
Ике йөз мең сөңгесе.

Дөнья тезгенен ураган
Чыңгызның кулы каты.
Казык йолдызга бәйләгән
Ул үзенең Күк атын.

Ул — Тәңре бусагасында,
Җирдә калган шәүләсе.
Күк белән аңлашып алу —
Җиһангирлар хәйләсе...

## I

*— Сугыш — суеш. Күпме кавем*
*Ут-кылычтан узачак.*
*Миңа кадәр шулай булган,*
*Миннән соң да булачак.*

*Бүтән кануннарны белми*
*Ил белән ил алышы.*
*Сөңге очында сынала*
*Халыкларның язмышы.*

*Сугышларсыз ил башының*
*Даны кысыр калачак.*
*Миңа кадәр шулай булган,*
*Миннән соң да булачак.*

*Мин илләрне яулый-яулый*
*Кан коюдан тыямын.*
*Җирдә солых урнаштыру —*
*Минем изге хыялым.*

*Күп кавемнәр ут вә кылыч*
*Телен генә санлыйдыр.*
*Андый илне көл итүдән*
*Башка чарам калмыйдыр.*

*Бөтен җиһанны яуласам,*
*Гөлбакча итәм Җирне...*
*Саулык бир, Күк, гомерле ит*
*Яуга чыгар яугирне!..*

## II

*— Адәм затын даһи итсәң,*
*Нәфесенә көч иңер.*
*Яулый калса бар Җиһанны,*
*Тәңре буласы килер...*

Пышылдаулы Тәңре сүзе
Гүя уттан яралды;
Зиһен сүрүен көйдереп,
Офыкларга таралды.

Хәтәр иде бу хакыйкать,
Бу — сыналу кимәле;
Кылыч йөзе кебек яшьни
Җанның ялангач мәле.

Аны һәрчак хөкем иткән
Изүе ачык дала.
Яшен ташын учлап туган
Сабый бит ул дөньяга.

## III

*— Яшермәдең асылыңны...*
*Адәм улы, фани зат.*
*Минем сынау зынҗырыннан*
*Котыласың, син — азат.*

*«Мин кодрәтле!» диеп яшәү —*
*Куктән иңгән фәрман ул.*
*Инсаннарның вөҗүденә*
*Үзем салган дәрман ул.*

*Җирдә яшәү уенының*
*Кагыйдәсен кем җиңгән?*
*Кайсы баһадирга язган*
*Бәхетле китү җирдән?*

*Кәрлә чорлар синнән соң да*
*Дан бишеген асырлар.*
*Җиңелмичә китүеңне*
*Кичерерме гасырлар?..*

*Шәрекъ—Гареб арасында*
*Син үткән юллар такыр.*
*Ун ел гомер өстим сиңа!*
*Ун елга ун яу кичәрсең,*
*Күк асты — сиңа чатыр.*
*Шушы ун ел дәвамында*
*Җиңеләсең бер тапкыр!..*

## IV

Тетрәп куйды Тимучинның
Дала сыйган йөрәге.
Мондый язмышлы гомернең
Бармы аңа кирәге?!

Шулай уйлады Җиһангир,
Салды көбә-күлмәген.
Тезләнде дала бөркете,
Күккә багып күзләрен.

*— Җиңелмичә китим Җирдән,*
*Ал җанымны Күкләргә!*
*Соңгы сугыш... Соңгы сулыш...*
*Даным калсын күкрәргә!..*

## V

…Саян таулары ягыннан
Офык йөзе яктыра;
Дәһшәтле хан урынында
Гап-гади карт утыра.

Шул мизгелдә Җиһангирның
Теләге чынга ашты,
Купты давыл. Телде яшен —
Күк белән Җир тоташты.

Соңгы теләк — күктән бүләк
Гомер бәрабәренә;
Яшен ташын учка кысып,
Ауды ул мендәренә.

Йөрәк тукталган мизгелдә
Күктән йолдыз атылды;
Сулкылдады янар таулар,
Күк капусы ачылды.

Мөнбәре дә, мендәре дә,
Ияр булды өе дә.
Ята Җиһангир җәсәде
Кар кебек ак киездә.

Тугыз чуклы ак әләмнәр
Моңсуланып иелгән.
Хушлашырга дүрт кыйтгадан
Дәүләтле ирләр килгән.

Лачын булып очып төште
Ханның актык теләге:
— *Каберемне белмәсеннәр…*
*Әйтсеннәр: ул үлмәде…*

«Үлем» дигән сүздән өстен
Диңгез атлы Җиһангир!
Аңа мәдхия җырлаган
Акыннарга илһам бир!

Шаукымлы даны таралыр
Яулап бөтен Җиһанны.
Озаттылар сыктап аны:
Күкләр — бирде, Җир — алды...

Чаларды дәвер чалымы,
Офыккача — ак дала;
Мең-мең җайдак таптап узды
Тетрәп чапкан атларда.

Йомылды җир бәгыренә
Япан дала кабере;
Җилләр үпкән байрагына
Күчте лачын гомере...

## ШӘРЕКЪ БИЮЕ

Җиләс залда тып-тын гына бии кызлар —
Бөек ханның сылу колыннары.
Иңнәреннән ага тау чишмәсе кебек
Кырык нурдан үргән толымнары.

Алтын пәрәвезле бөек гөмбәзләрне
Назлы аһәң күккә якынайта.
Кагыла моң күңелләргә, агыла моң,
Чиксезлектән урап кайта-кайта.

Фарсы келәмендә хан утыра карап
Каш астыннан кызлар тарафына.
Ни булган соң бүген, ни булган соң аңа —
Зәһәр уты сүнгән карашында?..

Хан утыра майлы кымыз тәме килгән
Каты мыек очын тешләгән дә.
Ачты аңа назлы аһәң бер хакыйкать:
Ул ирекле бары төшләрендә...

Хәнҗәр сабын кыскан көчле бармакларда
Затлы ташлы күпме йөзек кашы —
Ул көл иткән шәһәр, илләр-җирләр саны,
Тәгәрәгән күпме кеше башы!

Бөек хаким. Ул бит әмер генә бирсен,
Чумып тәхет көче ләззәтенә;
Буйсынуга мохтаҗ кырмыскадай җаннар
Аямыйча үзен утка керә.

Бүген менә ачты хакыйкатьнең күзен...
Меңнәрне ул әсир иткән иде.
Хакимлекнең, тәхет биргән мөмкинлекнең
Ул үзе дә колы икән инде.

Назлы аһәң уятты да куйды аның
Калын көл астында калган хисен.
Күз алдында — җәйрәп яткан япан дала,
Учак төтеннәре, кылган исе.

Тезелешеп бара дөя кәрваннары,
Ә ул уйный-көлә белгән малай.
Аның да бит әнисе бар сыеныр га,
Күктән төшкән изге түгел алай.

Менә хәзер атланырга иде дирбиясез
Һәм иярсез генә чаптарына,
Һәм кайтырга иде гөнаһларга ярлы,
Шатлыкка бай сабый чакларына!

Җиргә ятып бер елыйсы иде хәзер,
Карамыйча күктә Тәңре барга.
Тән сакчысыз, җан сакчысыз, вәзирләрсез
Чыгып китәр иде далаларга...

Көч-куәте үзен әсир иткән ханның
Бу тәнендә затлы кан елыймы?!
Буйсындырган да ирексез, буйсынган да...
Шушы — җирдә яшәү канунымы?!

Тамды шулчак, ханның күз яшьләре тамды
Алтын җепле чапан бәрхетенә.
Сискәнде дә кинәт...
Ерак малайчактан
Сикерде ул биек тәхетенә.

Кем искәреп калды?!
Бөркет караш эзли,
Үз ireгeн тоеп әле генә
Хозурланган ханны чиксез ярсу били,
Сынап карый күндәм вәзиренә.

Менә кем искәргән ханның күз яшьләрен!
Корбан сорап зеңли йөзек кашы —
Әмер биргән ханның зәһәр шәүләсенә
Карбыз булып төшә вәзир башы.

Аһәң тына... Кара елан шуып чыга
Һәрбер кызның кырык толымыннан.
Хан, күзләрен каплап, ярдәм сорый шашып,
Үзен әсир иткән үз колыннан.

# ЙОЛА

*Фатих Сәүбән улына*

Болгар җәмгыятендә
бик тә акыллы кеше үсеп
җитсә, «Бу — безгә артык.
Бу — Тәңрегә кирәк!» дип,
аны теге дөньяга озатканнар.

Шанлы ил улларын учта чөеп
Үстерергә мөмкин елларда
Сәер тозак корган борынгылар,
Хәтәр йола булган Болгарда.
Асыл адәм калкып чыга икән,
Сискәндереп халык диңгезен.
Тәхет тирәсендә шаукым купкан:
— Какшатмасмы дәүләт нигезен?!

Бу бит бездән артык акыллырак,
Сирәк зирәклеге — чамасыз.
Аягүрә басса, күпләр чүгә,
Мин! дигәннәр кала чарасыз.

Мондыйларга дәүләт чикләре дә,
Дәвер чикләре дә кысандыр.
Гаярь затка олы киңлек бирик!
Халык хуплар, халык ышаныр...

— Ул Тәңрегә кирәк!
Мәйдан гүли,
Гавам өчен олуг тамаша.
Бөек мәгънә салгач, ышандыра:
Күк әмере — гадел кан аша.

Мәйдан гүли. Олпат аксөякләр,
Иләмәннәр үзәк төркемдә.
Күндәм, тыйнак булганнарның башын
Бүкәннәргә куймый беркем дә.

Мәйдан гүли. Нинди бәхетле зат —
Тәңре үз катына сораткан.
Болгар иле күпме гали җанны
Яшьли шулай күккә озаткан.

Ил гөмбәзен иңгә салыр ирләр —
Алтын баганалар киселгән.
Хан бәкләре и тантана иткән
Бу йоланың канлы исеннән.

Нинди гөнаһ! Ходай исеменнән,
Саташтырып, изге саналу.
Баһадирлык бәла булган илдә
Тинтәкләргә кала дан алу.

Гөмбәзләрең кая, и Болгарым,
Күкләр каргыш көле сиптеме?
Телсез халык — сусыз балык булып
Яшәгез, дип хөкем иттеме?!

Шул дәверне уйлап килдем менә
Хәрабәле Болгар ярына.
Сабак бирми тарих сабаклары,
Шул ук ташка заман абына.

— Тәңрегә кирәк! — дип, йә, кем әйтер,
Мәгънә калганмы ул йоладан?
Калган икән... Бүген дә шул йола,
Тик астыртын калка яңадан.
(Сәләтледән курка һәр заман!)

Киләчәкне уйлап басып торам,
Әрем исе килә даладан...

*2004*

## АТЛЫ БОЛГАР ЯДКӘРЕ

Капкаларың ачыламы Көнкарашка;
Мәңгелек гамь уелганмы һәрбер ташка;
Җиһаныңда мондый кала бармы башка?!

Әй, аткынам, атым, аткынаем,
Томыласың,
Тояклардан очкын чәчрәп яна
Кытыкланып көлә япан дала.

Капкаларда усал җилләр кагышымы;
Тәкъдирме бу, әллә Ходай каргышымы;
Каракошлар дәррәү чукый һәр ташыңны.

Әй, аткынам, атым, аткынаем,
Ник дулыйсың,
Ияреңнән җайдак чәчрәп кала,
Кара сөрем яга япан дала.

Күкләр сорый: болгаттыңмы Болгарыңны;
Йә ашыгып кылычыңны болгадыңмы;
Үз башыңны үзең чабып куймадыңмы?!

Әй, аткынам, атым, аткынаем,
Канлы яшең
Әрем бәбәгенә чәчрәп тама.
Томан каплап җылый япан дала.

## ДАЛА КАНЫ

Таң бөркете иңрәп күтәрелә
Җилгә изү ачкан балбаллардан.
Чыңгыз ханның елгыр аргамагы
Кешнәп чапкан япан далалардан.

Өне килә ерак дәверләрнең,
Кемгә аны тою язмагандыр;
Гомер агачыннан башкаена
Әремле бал әрнеп таммагандыр.

Ялган зурлык яман хурлык булып
Кайта берчак тормыш уенында.
Балбал кебек изүеңне ачсаң,
Кысыр җилләр бары куеныңда.

Җанда дала җиле уйнамаса,
Карашыңнан учак кабынмаса,
Җәя тартыр бармакларың дәрте
Саз кылына назлы кагылмаса —
Сиңа иңмәс Күкләр ихтыяры,
Дәвер ябар хәтер капкаларын.
Язмас хәтта төшләреңдә күрү
Җир тетрәткән атлы чапкыннарын.

Атлы дастаннарга иелерлек
Дәрман бармы хисси төннәреңдә,
Тиңсез бөек дала поэмасы
Кайсы курган-кабер төпләрендә?

Уянырмы Турфан оазисы,
Алтай-Саян, Кыпчак далалары?
Балбал түшендәге тустаганнан
Чык-су эчә бөркет балалары.

Күзләрендә — кыя олпатлыгы,
Хәтер булып көйри дала каны...

*2006*



## БӘГЫРЬ ӨЗГӘЛӘНГӘНДӘ

Fuimus nòn sumus.
(Бар идек, юк булдык.)

*Латин әйтеме*

Аллаһның канат астында
Күпме урын дауладык.
Учакларга кырау тиде —
Дөрләп китә алмадык.

Каргалган туфрак ташларын
Кочаклады тамырлар.
Вакыт кабере — упкында
Күләгәне табырлар.

Кыямәт көне килгәндә,
Күктән әмер бирелер;
Идел тулып аккан каннар
Шаһитка әверелер.

Таркалган җаннарга карап
Ни әйтер соң Хөкемдар?
Хәрабәләр кайтавазы
Бары сыктап сулкылдар.

Бирелгән иде югыйсә
Тәңренең көч-фәрманы:
Кылдай кылыч йөзләрендә
Биетергә дөньяны!

Булмады...

Төшеп утыр инде хәзер
Тамырың төпкеленә.
Җиңелгән арыслан риза шул
Ишәкнең типкәненә.

...Шундый уйлар кайнап алды
Сыгылган күңелемдә,
Күз яшендә олыгаеп
Кояш баеган мәлдә.

*1997*

## ТАБАРЛАР БЕЗНЕҢ ЭЗЛӘРНЕ

Еланнан елау көтмә син,
Еланнан елау көтмә;
Елатыр елларны йолып,
Дөнья тетмәсен тетмә!

Уйлар уйла бер утырып
Елантау итәгенә.
Халкыңның гомер агачы
Күрмәде ниләр генә.

Текә язмыш маңгаена
Күпме әр, күпме яра?!
Янә яшәреп, еланнар
Иске кабыгын сала.

Иске кабыгын сала да
Ысылдап урап ала.
Эчкә елан йотканнарның
Җан күзе салкыная.

Аттила оныкларының
Учагы сүнеп бара.
Үрчи мөгезле еланнар,
Кыйтгалар ятка кала.

Еланнан елау көтмә син,
Еланнан елау көтмә;
Бүген җуйган зурлыгыңны
Үткәннән өмет итмә!

Табарлар безнең эзләрне,
Әйтерләр хәйран калып:
— Үзе үстергән еланнан
Чагылып үлгән халык...

*2005*

## ХОДАЙГА ДА БИК КҮҢЕЛСЕЗ БУЛЫР

Аргамаклар аягүрә басып,
Кешнәп ауган дәверләр сыман,
Убылыр татар тарих бәгъренә,
Легендалар калкыр җан сорап.

Бу — хыялда. Чынбарлыкта исә
Куеп карыйк гадел хөкемгә:
Горур үлә белү горурлыгы
Бирелгәнме безнең кавемгә?

Үзе теләп бетә бара халык,
Гүя үз-үзенә үч итә;
Ничә гасыр буе, чимал булып,
Төрле кавемнәрне үрчетә.

Бетә-бетә шулай бетә торгач,
Коргаксыр да язмыш казаны.
Торып калыр ялгыз бер могикан!
Бик гыйбрәтле булыр азагы.

Олыларлар соңгы могиканны,
Илләр буйлап зурлап йөртерләр.
Нинди бөек халык булган диеп,
Дөнья аңа карап фикерләр.

Ә көнчелек, татар көнчелеге
Бетәрме соң Җирдә, ниһаять,
Хәтәре дә бетсә, татары да,
Нинди хәлгә калыр бу хәят?

Юк. Тагын да татар бер калкыныр,
Соңгы могиканнан көнләшеп,
Үрчи башлар соңгы могиканнар,
Тешләшеп тә янә үчләшеп.

Бәхәс кубар, әрсез могиканнар
Төрле кыйтгаларда дан алыр.
Иң актыкта мин беренче дигән
«Татар чире» Җиргә таралыр.

Ә барыбер соңгы могиканга
Бетү чираты бер җитәчәк.
Күзгә кырып салыр татар беткәч,
Киләчәксез калыр киләчәк.

Ходайга да бик күңелсез булыр,
Галәм үкенечен татырлык:
— Җирдә бармы тагын берәр халык
Саллы исем белән атарлык?!

Менә шунда инде яңабаштан
Уйлап чыгарырлар татарны!

*2007*

*Җырладым сине. Җырыңда*
*Үземне танымыйм, димә.*
*Үзем тудырган үзеңә*
*Син ышан. Соклан. Тимә!*





## ХӘНҖӘР

Җилдәш булып сарыл әйдә
Ялына хыялымның.
Йөрәккә керсен хәнҗәре —
Мәхәббәт кыягының.



## ҖЕ-ҖЕ

Җил кызы килә җилкенеп,
Җиксемә, җикән камыш,
Җаникә җуйган җырларны
Җилбәзәк җилдән табыш.

## БУРАНДА ШЫТКАН ГӨЛ

Бер кыз тора буран эчендә.
Кушыл әйдә, кушыл бураннарга,
Шул кызны бер күрер өченгә...

Ярсу буран куенынннан шытып,
Тере чәчәк булып калыккан.
Әллә инде хушлашмый да китеп,
Әллә инде көтеп зарыккан.

Бер кыз тора буран эчендә.
Тыйма,хыял, тыйма бураннарны,
Шул кызны бер күрер өченгә.

Бураннардан йолып алыйм дисәм,
Сүнәчәкме, дәшсәм... бу чәчәк?
Ерак та ул миңа, якын да ул,
Әллә — узган, әллә... киләчәк?..

Бер кыз тора буран эчендә.
Бу дөньяда яшәвең дә ярый,
Шул кызны бер күрер өченгә.
Бер кыз тора буран эчендә.

## ХӘТЕР ТАВЫНДА

Син, дисәм…
Чыңлый күңелнең
Көмеш кыңгыраулары.
Җилкенеп калка гомернең
Аргамаклы еллары.

Син, дисәм…
Исемең серен
Беркемгә ачмасам да…
Иң ләйсәнле гөл кабына
Исемнәр бакчасында.

Син, дисәм…
Җиләкле җилне
Кушып үргән толымың
Искә төшеп урап ала,
Шул толымың колы мин.

Син, дисәм…
Хәтер тавында
Яшеннәр бәрелешә.
Бу — гомерлек якты әрнү —
Гел ерак, гел янәшә.

Син, дисәм…
Иң чытлык йолдыз
Чаткылап күкне бизи.
Син киткән эзләрне үбеп,
Тәкъдир миңа кул изи…

*2006*

## ТӘКЪДИР

Күндәм гашыйк колың булып,
Имәс башны исәм дә;

Көнчелекнең кара кошын
Упкыннарга чөйсәм дә;

Йолдыз алып бирәм диеп,
Кыяларга менсәм дә;

Җирдәге оҗмах капкасын
Ачып түргә үтсәм дә;

Алтын тәхетләрне биләп,
Ханнар таҗы кисәм дә;

Тургай сулышы кабарлык
Җырлар иҗат итсәм дә;

— Барыбер ярый алмассың! —
Тәкъдирем әйтә көлеп.

Аллаһтан узып яратсам,
Сине җуярмын кебек.

*2005*

## КАР АТТЫҢ ТӘРӘЗӘМӘ

*(Кыз җыры)*

Күңелемнән саный идем
Синсез үткән көннәрне:
Тәрәзәмә кар аттың да
Сискәндердең гөлләрне.

Күз салмам дигән идем дә,
Күз салдым шул нигәдер.
Тәрәзәмә карың түгел —
Йөрәк җылың тигәндер.

Мин көткәнмен. Син килгәнсең,
Ярсу атлар капкада.
Әллә елыйм, әллә көләм,
Йөрәк тынга каплана.

Гашыйк егет, йолдыз төреп,
Тәрәзәңә кар атса,
Йөгереп чык та капкаңны ач,
Бәхет керсен пар атта!

## УРМАНЧЫ КЫЗЫ

Челтәр шәлең — иңнәреңдә,
Челтәр кояш — чиләгеңдә.
Кулыңдагы ефәк йомгак
Нинди бизәк чигәреңә?
Сусадым дип нигә генә
Иелдем соң чиләгеңә?

*Кыңгырау гөл чылтыравы*
*Синең көлү-елмаюың.*
*Мөлдерәмә чиләк белән*
*Каршы чыктың,*
*Уңар юлым,*
*Уңар юлым…*

Челтәр шәлең — кулларыңда,
Челтәр кояш — юлларыңда.
Югалттыңмы җеп очларын
Тәгәрәгән йомгагыңда?
Шул йомгакны эзләп табыйм,
Син адаштыр урманыңда.

*Кыңгырау гөл чылтыравы*
*Синең көлү-елмаюың.*
*Мөлдерәмә чиләк белән*
*Каршы чыктың,*
*Уңар юлым,*
*Уңар юлым…*

## ТҮГӘРӘК АЛАНДА

Кояш күлмәгеннән калып,
Бии-бии кыргыйландың.
Син — бу көннең алиһәсе!

* * *

Синең аяк асларында
Тапталуны бәхет санап
Аңын җуйды чәчәкләр.

* * *

Такыядан таҗ кидердем,
Аяк очларына басып.
Алкышлады сине урман.

## ӘЙ

Нинди уйлар яфрак ярды
Күңел ешкынлыгында?
Күзләреңдә — яшел яшен.

* * *

Син яратып чагасың шул:
Уклы сүзең яралый да,
Сутлы сүзең дәвалый.

## ТАМЫРЫНДА...

Чишмәгә сереӊ сөйләп,
Утырып бер еладыӊ.
Дулкынланды ерак диӊгез.

* * *

Безнеӊ мәхәббәт көчеге
Бии учак йөрәгендә —
Үрә колаклы ялкын.

* * *

Бик сагынган чакларыӊда
Гөлеӊ чәчәк атамы?
Тамырыӊда — минем кан.

## АВГУСТ ТӨНЕ

Яшеннәрдән камчылатып,
Тау башында йөргән идек.
Аһ, ул хәтәр төн хәтере!

* * *

Артык бәхеттән исергәч,
Бергә үлик дигән идек...
Аерым-аерым исән калдык.

* * *

Галәм чатыры астында
Үләнле тау мендәрендә
Кабындык без йолдыз яңгырыннан.

## ЯРАТЫП КИСӘТҮ

Күзең каты,
Күккә бакма,
Йолдызларның күңеле нечкә.

Изүе ачылыр да Күкнең
Бар да калыр үкенечкә.

## ЯШЬЛЕК

Чыкты бәреп араннарны
Бу яшьлекнең тай чагы.

Зеңләми алтын кыңгырау —
Кесәләрнең сай чагы.

Тауны тауга сөзештерер
Хыялларның бай чагы.

Керфек кагудан кабынды
Бакый сөю учагы.

Валлаһи, дим, бүтән иде
Кыйгач Айның таҗ чагы.

Соңлап кергән акыл әйтә:
— Сиңа ни кирәк тагы?!

## ХӘТӘР МИЗГЕЛ

Дөнья яры күмелгәнче
Йөзеп керәсе иде;
Төнге дәрья кочагында
Ялгыш... үләсе иде.

Тып-тын гына. Кычкырмыйча,
Күкләрне калтыратып;
Ярда учак ягып калган
Дусларны аптыратып.

Күтәрелсен иде җаның
Җиһан-галәм катына.
Канатларын киереп, җан
Алгысына, атына.

Тәңре утырган тәхеткә
Йолдызлы юл түшәлгән.
Мондый илаһи киңлектән
Кем соң кире төшәлгән?!

Мин очам, очам тирбәлеп
Төнге күк уртасыннан.
Кинәт... Кычкырган тавышка
Учаклы яр астыннан
Убылам күк катларыннан
Алкалы дулкыннарга.
Калтыранып куя тәнем,
Чыгасы килми ярга.

Ирек беткәнен аңлый җан
(Иртәрәк бит әлегә)...
Йолдызлы күк аланыннан
Читлеккә кайтып керә.

Ә син ярда. Куркынгансың:
— Кычкырам... Син югалдың,
Мә кайнар чәй, туңгансыңдыр.
Баттың диеп уйладым... —
Иңемә сөлге салдың.

Сүзләр дисбесе таралган,
Бер мәлгә телсез калдым.
Минем бары гәүдәм генә
Җиргә кайтты бит әле.
Күзләремдә — йолдыз җене,
Ирендә — галәм тәме.



## БЕР...

Бер сөясең, бер көясең,
Бер елыйсың, бер көләсең —
Сине ничек юатыйм соң?

Бер сүнәсең, бер янасың,
Бер китәсең, бер каласың —
Сине ничек югалтыйм соң?!

## МИН АШЫГАМ

Чишендереп киткән чакта көзләр,
Елап калган иде чаганнар.
Бүген алар, кышка кочак җәеп,
Тагын ап-ак яфрак ярганнар.

Ак гөлләре кышның, ак төннәре...
Әкият булып сергә төренгән.
Артта эзләр, зәңгәр чылбыр гүя,
Китеп барам кара киемнән.

Артта зәңгәр эзләр генә юкса,
Ә мин менә кара киемнән.
Искергән бу дөнья хәйләләргә,
Хыянәтләргә, ахры, күмелгән.

Сиңа таба барам — яктыруга!
Гүя син ул яңа кояшым.
Кем дә кагылмаган утравым син,
Ярларыңа салыйм бу башым.

Бер иркәлә! Мең кат иркәләнгән
Һәм хыянәт кискән йөрәкне.
Каян белгән язмыш шушы мәлдә
Синең миңа болай кирәкне.

Бер яктырып китә синең көлү
Ак чаганнар аша савылып;
Мин ашыгам. Дөнья кинәт бетәр!..
Өлгермәм күк сиңа сарылып.

## ЯЗМЫШ

Бу дөньяда синең белән
Бер сукмакта танышканбыз.
Кайсы йолдыз кемгә диеп,
Жирәбәләр салышканбыз.

Бер тәүлеккә айрылсак та,
Кайнар хатлар алышканбыз;
Ахрысы, без мәхәббәттән
Авыруга сабышканбыз.

Ә беркөнне, ә беркөнне…
Юктан гына ялгышканбыз.
Хатларны да, хаталанып,
Учакларга ягышканбыз.

Үзебез дә белмичә без
Йөрәкләрне алышканбыз.
Бүген менә еллар аша
Кабат килеп табышканбыз.

Кадерләрне белеп кенә
Бүген менә кавышканбыз.
Ул чагында айрылышып
Ничек дөрес ялгышканбыз.

## КАЯ СОҢ?..

Көнләшергә әзер торган
Күңелнең гамьлелеге;
«Син генә» дигән чакларның
Самими гаделлеге.

Хәтердә сыктап яңара…
Сер бирми шул мин-минлек.
Кабат алданырга, язмыш,
Бир тагын бер мөмкинлек.

## УТ АЛМА СИН ШӘМДӘЛЛӘРГӘ

Күзләреңдә — төнге учак,
Җылыт әйдә арган җанны.
Мин онытгым бугай инде
Бәхет юрап узганнарны.
Пышылда син ягымлы сүз,
Җылыт әйдә арган җанны.

*Ут алма син шәмдәлләргә,*
*Кагылма син шәүләләргә,*
*Ай нурында коенсыннар.*
*Мәхәббәткә соңардык дип*
*Кыенсынма, кыенсынма...*
*Тәрәзәгә сарыла җил —*
*Сары яфрак явымнары...*
*Ярый инде, шөкер итик —*
*Безгә бәхет кагылмады.*
*Тәрәзәгә сарыла җил —*
*Сары яфрак явымнары...*

Бүген безгә бирелгәнме
Мәңгелекнең бер мизгеле.
Гөнаһлардан арган җанны
Кочып алсын бер изгелек.
Пышылда син ягымлы сүз
Мәңгелекнең бер мизгеле...

*Ут алма син шәмдәлләргә,*
*Кагылма син шәүләләргә,*
*Ай нурында коенсыннар.*

*Мәхәббәткә соңардык дип*
*Кыенсынма, кыенсынма...*
*Тәрәзәгә сарыла җил —*
*Сары яфрак явымнары...*
*Ярый инде, шөкер итик —*
*Безгә бәхет кагылмады.*
Тәрәзәгә сарыла җил —
Сары яфрак явымнары...

## САКЛА, ХОДАЙ

Хәтер аръягыннан, кулың болгап,
Күптән инде төшкә кермисең.
Аланнарның алиһәсе булып
Такыялар үреп кимисең.

Күрәсе дә килә, күрмисе дә...
Шундый юләр уйлар күңелдә.
Гөнаһ дигән көчек койрык кыссын,
Без бит фәрештәләр түгел лә.

Кайда соң ул без таянган үрләр —
Кояш чыккан, кояш баеган.
Сүз таҗыннан такыялар үреп,
Үкенечкә калган поэмам.

Шул үрләрдән кычкырасы килә:
— Без кавышкан урын шушында-ау!
Кайнар тынга каба рәхәт сүзләр,
Колакларда бәрхет пышылдау.

Хис кузгалса, акыл тышаулана,
Булмый — әүвәл, булмый — аннары...
Без бит мәхәббәттә гөнаһсызлар,
Күк-Тәңренең күндәм коллары.

Төштәге «син» белән өндәге «син»
Таныр иде микән бер-берен?
Еллар аша ничек кичеп чыгыйм
Күрешүдән курку күперен.

Чакырам да сине, чакырмыйм да
Без калдырган шалаш-ояга.
Сакла, Ходай, күрешүне әйдә
Калдырыйк без теге дөньяга.

*2006*

## ХӘТЕР БУРЛАГЫ

Чибәрләнә, чытлыкланa кызлар,
Кытыклана күңел кыллары.
Уйлары да бүтән, туйлары да...
Бу балга син — дегет нибары.

Юанычка дәва — бу гомернең
Булачагы түгел, булганы.
Үткән заман фигыльләрен, кайтып,
Сөйрә әйдә, хәтер бурлагы.

*2006*

## УНСИГЕЗДӘ ЯЗГАН ХАТЫҢ

Нинди садә, рәйхани язу,
Картлык ничек шәрехләр?..

Саргайган елларны үчекләп,
Бии япь-яшь хәрефләр.

*2004*

## ТЕЗГЕНСЕЗ СОРАУЛАР

Елларны кагынумы бу,
Хисләрдән башларны җуеп,
Алданып талпынумы?

Рәхәт бер кабынумы бу,
Тәүге назларны хәтерләп,
Өметсез сагынумы?

Бәхетле абынумы бу,
Чумып, яшь тән ләззәтенә
Аяусыз табынумы?

Яшәүнең талымымы бу,
Кул изәп китеп баручы
Мәхәббәт канунымы?

*2006*

## ӘЙЕ, БЕЛӘМ

Тартып өз гомер дисбесен,
Чәчелсен төймәләре!
Давыллап ярга бәрелсен
Язмышым көймәләре!

Мондый гүзәл каршында мин
Үткәнемнән ваз кичәм.
Юаш яшьлектән сузылган
Юллар каешын кисәм.

Мондый гүзәл каршында мин
Сукмак булып түшәләм.
Балдагының кашына дип
Айны алып төшәләм!

Ә ул көлә-көлә бии,
Еланнан елдам сыны.
Сулышка кабыр гүзәллек —
Иблисбикә токымы.

Кыргый ау дәртен кузгата
Елмаюлы бер ымы...
(Күпләр кызыгып күзәтә
Ничек бетәр дип соңы.)

Беләм... Әйе, белеп үләм,
Бу — акылсыз хәрәкәт.
Соклanудан саклану юк,
Бу — бәхетле һәлакәт.

## МӘХӘББӘТ БАЛДАГЫ

Килмә син, килмә күңелгә,
Күңлемдә үкенеп күмелмә;
Айның да сул ягы — күгемдә.

Манма булырсың да хисләреңнән,
Әрнү килер әрем исләреннән.

Кайтма син, кайтма кабаттан,
Күпме җан канатын канаткан:
Бу Җирдә Иблискә таң аткан.

Манма булырсың да сагышыңнан,
Үкенерсең гадел ялгышыңнан.

Китмә син, китмә хәтердән,
Мәңгегә калырга әзерлән:
Гөл булып шытарсың кабердән.

Манма булырсың да яңгырларда,
Елмаерсың... бер өн яңгырар да...

*2007*

*Җәйнең яшел куенына керәм,*
*Көяз чикерткәләр җыр көйли.*
*Тау күкрәкле, туган җирем, синдә,*
*Җанны алгысытып, чор гүли.*





## БЕР АДЫМ

Җан канатын киерәдер
Туган якның тау җиле.
Күккә бер адым калгачтын,
Борылдым әле кире…

* * *

Тау кикриге булып син
Басып тор тау башында.
Гөнаһларың әтәч булып
Кычкырып куяр шунда.

* * *

Керкәле тауда йөргәндә,
Әллә каян искә төште
Кракатау вулканы.

Кыйтгаларда безнең телдән
Тамган күпме сүз каны…

## КОЯШ КАПКАСЫ

Көн туа. Кояш капкасы
Чатыр тауда ачыла.
Шул капкадан ыспай басып,
Көн колыны — Таң чыга.

Ялларын җилпеп ала да
Баса ул аягүрә.
Кытыкланып уяна җир,
Таң тоягы тиюгә.

Чык төсләре яшьнәп китә
Тауларым итәгеннән;
Таң җиле тыйнак яратып
Чәбәкли битләремнән.

Офыкларда — бөдрә дулкын,
Урманнар — яшел күбек.
Яшьлегең шул яшеллектә
Адашып яши кебек.

И туган җир! Синдә генә
Дөньямның көйле гаме.
Җиләндә җиләк тәме шул,
Җиләндә җиләк тәме.

Их, мәтәлчек атып уйнар
Таулар да олыгайган.
Чатыр тауның маңгаена
Нинди сүрә язылган?

Шул сүрәне укыр өчен
Бармы тел ачкычларың?!
— Бар ул миндә, миндә! — диеп,
Очынып әйтер чагың.

Артык бәхеттән исермәс
Өчен бар шундый йола:
Тауның бәрхет мендәренә
Каплан да... ела, ела...

Бушанып калкыр да җаның
Колачлар тау галәмен.
Бу — синең соңлап уянган
Гамьле-иләсле мәлең.

...Кояш капкасын ачканда
Ишеттем шыгырдавын,
Шигъри сүзләрне ашыгып
Уяттым бугай тагын.

Ярлыка, туган ягым!..

*2005*

## БИЕКЛЕКНЕҢ ИЗҮЕ АЧЫК

Чатыр тауда, чатыр корып
Зәңгәр күк гөмбәзеннән,
Утырдык без, һәммәбез дә
Шагыйрьләр өммәтеннән.

Әйтерсең лә Күк тәхете,
Дөньялар бик түбәндә.
Биеклеккә тиз күнегә,
Онытыла шул бәндә.

Нишлисең, таудан чөйдереп,
Биек буласы килә.
Тыйнак кәпәчне болытка
Элеп куясы килә.

Хәмер түгел, йомшак җилдән
Йөзләргә нур коела.
Кара йөзле шагыйрьләр гел
Юктыр кебек тоела.

Андыйларга тау йөрәге
Мәрхаба! дип типмәстер.
Болыт агына мансаң да,
Йөз карасы китмәстер.

Бу көн безгә бирелгән лә,
Һәр мизгелен отып кал!
Күкнең зәңгәр аланында
Бөдрә сарык болытлар.

Олпат тауда — уй учагы,
Ягымлы җил кагышы.
Айгыртаулы Туфанның[1] да
Тышаулы көр тавышы.

Гөнаһ язар фәрештәнең
Чабуына утырып,
Талгын гына гәпләшәбез...
Тау да тыңлый йотылып.

Хозыр Ильяс кебек тора
Баш очында ак болыт.



[1] Туфан Миңнуллин.

## БЕР КӨНЛЕК ГОМЕР

Йолдыз нурлары калтырый
Иртәнге көмеш чыкта.
Өянкеләр башын ия,
Күке кычкырган чакта.

Күке кычкырган чагында
Нигә соң дөнья моңлы?
Затлы тавышын көйләгән
Сандугач хәтта тынды.

Ә син санама гомереӊ,
Туган як моңын тыңла.
Тыңла да җаныңа сеңдер,
Мәгънәсен сүзсез аңла.

Купшы залларга китереп
Күкене тыңлап кара —
Өянке, инеш, болыннар
Бар моңын алып кала.

Туган җир моңы. Елларны
Санама. Тыңлап кара.
.................................
Бер көнлек озын гомерле
Күбәләк очып бара...

*1981*

## ӘБИЛЕ ЙОРТ

### I

Салып куйган читекләрен
Оя итеп йомарланган
Песи дигән иркә-көяз
Җылы йомгак балалары.

### II

Намазлыгына текәлгән.
Ә йөзендә нурлы рәшә.
Авазлардан чигә мәкам,
Өйне сара ак иминлек.

### III

Әфсенен соң аңладым:
Үзе ачкан чакта гына
Серле булган сандыгы…

## ШӘҺӘРДӘ НӘҮМИЗ ХӘТЕР

Сагындыра горур шайтан таяклары;
Нөгештәге үткен курән кыяклары.

Чишмә төбендәге җем-җем чуерташлар,
Бишташ кебек чәчелгәнбез, уендашлар.

Ак тузанлы Пауыл дәдәй тегермәне,
Алмалары — тупыр-тупыр өлгергәне;

Сагындыра төнен бүре улаулары,
Кар сайратып үткән бәсле олаулары.

И ярышып ат җигәргә өйрәнүләр,
Аулагөйләр чиратына көйләнүләр...

Йөзек салыш, йолдыз санау уенында,
Тәүге үпкән кунак кызы — куенында.

Бар иде бит һәр авылның бер җүләре,
Бер җүләргә тормый хәзер мең җүләре!

И ул чорның садә-газиз ярлылыгы,
Бай күңелгә уртак иде бары-югы.

Тыңлый идек сугыш кичкән агайларны,
Якын иде Берлин — Балтач аралары.

Стәрленең суы, димә, тездән генә,
Тоташкан ул ерак Каспий диңгезенә.

Бәхилләә син безне, хәтердәге авыл,
Атлантида кебек күмде сине давыл.

Нәүмиз еллар... Бар да калды аргы ярда,
Узган гасыр... Юллар инде бармый анда.

Юлым бүлә урамнарның ак сызыгы,
Учта — асламчыдан алган таш сыбызгы.

*2004*



## ТУРГАЙ БИЕКЛЕГЕ

Җилләр көрмәкләшкән карлы кырлар
Оеп яткан төнне киерә.
Сары көчек булып, тотам калмый,
Чана эзләреннән ай йөгерә.

Сыкы ява йолдыз тузаныдай,
Ат сыртына сарган салкын бәс.
Гомер кебек җилеп кенә үткән
Кышкы юлны кемнәр сагынмас.

Җирән кашка дугаларын күмеп,
Ак тын бөркеп җитез юырта.
Ә чанада, толып аша карап,
Кырын яткан малайчак кайта.

Өлкән агай каеш дилбегәсен
Кагып ала, тизлек үзгәрә.
Ә үзе гел бер җыр көйләп кайта:
— Ирмен дигән ирләр түзә лә...

Җырга куша тагын тургайларны,
Җәйге җырлар били күңелне.
Моңсу көйне ят итмәгән малай
Черем итеп бара түгелме?..

Тояклардан купкан кар тузаны
Биткә бәрә, аны сизми ул.
Агай тынып калгач, моңлы көйне
Дәвам итә төштә, өзми ул.

Төнге юлның соңы җитеп килә,
Ә малайҗан — татлы төшендә.
Тургайларга кадәр очып менгәч,
Уяныр ул толып эчендә.

## ҖӘЯҮЛЕ БУРАН

*Кунак булып менә*
*Тыйнак көйгә генә*
*Уйнап китәбез дип,*
*И агыла җәяүле буран.*
*Мондый чакта кырга чык, туган!*

Ак ялкыны дөрли кырларымның,
Ак ялкыны — атлар тезеннән.
Кем көйли бу талгын хәрәкәтне,
Җибәрмичә җилне тезгеннән.

Басып торам кырлар иңендә мин,
Бормаланып буран агыла.
Балачактан кайткан көчек сыман,
Аягыма килеп сарыла.

Бу — хәбәре генә. Чын бураннар
Үрә басып килер, хәтерлә!
Кырлар иңен иркә генә сыйпап,
Җәяүлесе үтә хәзергә.

Кыш үзенең аклы моңсулыгын
Толым-толым үреп тарата,
Биштәр асып җәяү киткән яшьлек
Адашкандыр кайсы тарафта?

Әй бураным, юаш мосафирым,
Күчмән холык каян киләдер.
Яратып та, таратып та карап,
Язмыш бездән шулай көләдер.

Кичер мине, ятим калган нигез,
Җылы ташың күчәр кальбемә.
Рәхмәт сиңа, җәяүле бураным,
Сыктап, сыкыланган күңлемә
Изге елан булып уралдың да
Юаттың син кереп хәлемә...

*Юаш кына димә,*
*Юлдаш булдык менә,*
*Моңдаш икәнбез дип,*
*И агыла җәяүле буран,*
*Мондый чакта кырга чык, туган...*

*2006*



## КАБАТЛАНМАС ӘКИЯТ

Авыл өе. Келт-келт сәгать йөри,
Тукмагына кайчы асылган.
Бозлы тәрәзәдә кояш көлә,
Төнге буран инде басылган.

Әни оек бәйли түр сәкедә,
Сайлаган ул җепнең иң агын.
Ыспай гына сикергәләп, песи
Тәгәрәтеп уйный йомгагын.

Әти әнә түгәрәк бер көйгә
Пычак кайрый шундый бирелеп.
Ә мин, торып, уятырга диеп,
Әлифбамны алам үрелеп.

«А» дан «Я» га таба китәр малай
Белми алда ниләр буласын.
Аңа ни лә: аю ишек каксын,
Төлке килсен, бүре уласын!

Менә хәзер... Мичтән чыккан иснең
Хозурлыгы өйгә тарала.
Ак сөлгедә — арыш ипиләре,
Нәни шишара бар арада.

Бусы инде сиңа, малайчагым,
Әнкәң куя аны сындырып.
Кайнар булы ипи, сап-салкын сөт
Тәме тәнгә күчә, сыгылып.

Тук малайга нәрсә, уен кирәк,
Бишмәте дә әнә өр-яңа.
Өйалды сайгакларын «сөйләштереп»,
Дәррәү кубып чыга урамга.
(Иярәм дип, песи — Йөнтәс койрык —
Ишеккә чак кысылмый кала.)

И ак хәят! Көртләр,сырындылар
Хәл җыядыр талып йокыга.
Кояшның да бүген колагы бар,
Ул да мохтаҗ җылы якага.

Мендәргә баш төрткән песи кебек,
Өйләр кар көртенә сыенган.
Морҗаларда төтен — йөнтәс койрык —
Күксел сыкы-нурга коенган.

Кәбестә күк тыгыз кар шыгырдый,
Бар да сулый бөркеп ак тынын.
Кайда соң син, гадел-ярлы авыл,
Кирәкми бит миңа артыгы:
Бу әкият кире кайтсын өчен
Бирер идем дөнья алтынын.

*2005*

## БОРЫЛЫШ

Яшьлек кыңгыравы алынган
Пар атлар дугасыннан.
Сабырлык сирпелә урманның
Наратлы догасыннан.

## ТОРНАЛАР ТӨШКӘНДӘ

— Торыйк! — диеп, сузып-сузып,
Күк битенә сөрмә сызып,
Сагынып кайта торналар.

— Күлем кая?
Күгем — анда.
— Күгем кая?
Күлем — анда...
Буталдымы сагынудан
Туган як манзарасы.
(Дога кыладыр алар да,
Кошларның үз Алласы...)

Канатыннан кага-кага
Мадагаскар тузанын,
Күкнең зәңгәр басмасыннан
Төшә торна кәрваны.

Чигенегез, әй, тауларым,
Ышыклагыз, әй, талларым!
Йөрәк биеклеге калды
Канат шыгырдаулары.

Торна биегән туйларны
Тиздән күрер кырларым.

Уйсуланды уйларым...

*2003*

## НӘФЕС

Җитәр, диеп ничек әйтим…
Кәккүк миңа гомер саный
Стәрле таллыгында.

Яшәүгә нәфес туялмый
Балачак коллыгында.



## ТУРГАЙ ШӘҮЛӘСЕ

Кояш тажы кигән Күк астында
Моң бәбәге — тургай очына.
Җәй догасы шушы нәни кошның
Бисмилласы белән ачыла.

Көмеш телле кошчык сибә генә
Игеннәргә шифа сүрәсен.
Бу — бәхетле нокта. Башны чөям,
Учка кысып тургай шәүләсен.

## БӘХЕТНЕҢ МАЛАЙЧАГЫ

Их!
Карбызны урталайга ярып,
Колакларың күмелгәнче
Бәрхет шәфәкъка чуму!

Янәшәңдә мүкләк бозау
Кызыгып дәшәр: «Му!.. Му!..»

## КӨЗГЕ КОШЛАР КӘРВАНЫ

Өмәләшеп, күмәкләшеп,
Кояшның тузанын кагарга
Очып китәләрдер кебек.

Болытлар — күбек, күбек.



## МИН КӨТҮЧЕ БУЛАМ, ДИГӘН ИДЕМ

Карашымны күккә юнәлтәдер
Таныш сукмакларның азаюы.
Һаман шулай, авыл турысыннан
Агып бара Киек Казлар юлы.

Чигенә сулар, агышларын борып,
Иске ярын хәзер белә кемнәр?
Казлар кебек бер аякта басып
Йокымсырап тора өянкеләр.

Мин хуҗасы идем бу төбәкнең,
Чикне белми иде хыялларым.
Менгән саен тормыш баскычыннан
Сагындыра артта калган ярым.

Мин көтүче булам, дигән идем,
Кичерегез, кырлар, тугайларым,
Китеп барсам да мин еракларга,
Тугры калдым сиңа, туган ягым.

Үткәннәрем инде – бүтән дөнья,
Яд итәдер хәзер үзгә көннәр.
Пәке белән уйган исемнәр юк –
Коймаларга кадәр үзгәрткәннәр.

Сөялгәнмен хәтер агачына,
Чиксез күктә — таҗын ачкан өмет.
Җәйрәп ята чыклы йолдыз юлы –
Таңда көтү киткән эзләр кебек.

## ШАГЫЙРЬ КЕРГӘН УРМАНГА

Сакауланган кәккүк белән
Җәй моңы китә генә.
Пеләш гөмбәләр үреләә
Яңгырлар итәгенә.

Поши мөгезе үреләә
Пәрәвез ятьмәсенә.
Мөгезнең дә ниндие бит! —
Унике япьлесенә.

Зәһәр аучы ядрәсеннән
Унике ел сау калган.
Олпат поши гомере бу —
Сакланганны саклаган.

Башың иеп сәлам бир син
Шау урман хуҗасына.
Сак атлап бар, төшә күрмә
Бүреләр убасына.

Чүгәр җаның, урман шомы
Чишәр курку төенең.
Сакауланыр да шигырең,
Моңы качар телеңнең.

*2005*

## УЙЛЫ УРМАН

Ак телдә пышылдый каеннар:
— Мәгънәле үтәме бу еллар?

Күз туе — ахактан усаклар:
— Кая соң сез яккан учаклар?

Җилләрдә бөгелми имәннәр:
— Ник ирләр башларын игәннәр?

Горур да, мәгърур да наратлар:
— Калдымы яд итәр ир-атлар?

Иелеп эндәшә чаганнар:
— Килдеме вөҗдансыз заманнар?!

Мең телдә кисәтә урманым:
— Кермә син бу яшел хәятка,
Кермә син, гөнаһка уралып.

*2006*

## ТОМАНЛЫ АВГУСТ ТАҢЫ

И иртәнге хозурлыклар яме!
Тугайларга томан тулышкан.
Иркәләнеп кенә калка Кояш,
Җир кинәнә сөтле сулыштан.

Җилгә әле уяныргга иртә,
Бисмиллалы таңның үз мәле,
Яшәү дигән галибанә мизгел:
Иреннәрдә — сабый көз тәме.

Гөмбәләрнең колагыннан тартып,
Агып бара август томаны.
Тәһарәтле таңы табигатьнең,
Зеңләп куя көмеш комганы.

*2006*

## СЫКТАУ

Туган җирем тургай булып
Сыйган күңел читлегенә.

Әреме дә гөл генә шул,
Әреме дә гөл генә...

Нигез ташы чума бара
Караңгы җир күгенә...

## СОҢГЫ... НИНДИ ХӘТӘР СҮЗ

Хыялымда, качып кына,
Туган як, сиңа кайтам.
Кайтам да, тауларга менеп,
Җилләргә кырын ятам.

Аланнарыңа чыгам да
Боланнар булып чабам.
Урман шауларына чумып,
Шүрәле булып чыгам.

Танымаса малайчакны,
Бал корты булып чагам.

Тагын әллә ниләр кылам,
Бил алышам җил белән.
Дөлдөл ялына тотынып
Җиләм таулар иленнән.

Туган як манзарасында
Кинәнеп хозурланам.
Күк-коедан йолдыз эчеп
Торган малай мин булам!

Әнә шулай хыялымда
Кайтам да, кайтмый калам...

Берчак дәшәрмен пышылдап:
— Туган җир, мине чакыр!
Мин соңгы тапкыр кайтырмын,
Киталмам... соңгы тапкыр...

*2005*

## ВАСЫЯТЬ

Пышылдады миңа туган җирем,
Җил сыенды килеп күкрәгемә:
— Пәрәвез җебен өзә күрмә син,
Әниеңнән алда үлә күрмә...

*Ничек кайтмыйм ди сагынып,*
*Башкаламда аш кала.*
*Олыгайса да уйларым,*
*Хыял һаман яшь кала.*





## ӘРЕМ ИСЕ

Кыргый җил кергән Казанга
Бик ерак далалардан.
Йөри ул сыйпап Кешене,
Ярату — балбаллардан.

Даланың бөек серләрен
Сөйләргә тели микән?
Яңа гасыр мәйданында
Тиңдәшен эзли микән?

Мин чумам җил диңгезенә.
Ватанны сөю хисен
Тоймаганнар сизә микән
Шул җилдән... әрем исен?

## КАРЛЫ КАЗАН

Казаныма ява карлар, алгысынып,
Күңелләрдә нидән болай ак моңсулык?

*Төнге буран уйный урамнарда,*
*Бүре исе килә бураннардан,*
*Өне — ерак, кара урманнарда.*
*Бер... сулкылдау килә... узганнардан.*

Казанымның бүген менә шундый мәле...
Шуып төшкән иңнәреннән мамык шәле.

*Төнге буран уйный урамнарда,*
*Бүре исе килә бураннардан,*
*Өне — ерак, кара урманнарда.*
*Бер... сулкылдау килә... узганнардан.*

Тәрәзләрдә кар челтәрле абагалар —
Казаныма Күктән иңгән ак догалар.

*Төнге буран уйный урамнарда,*
*Бүре исе килә бураннардан,*
*Өне — ерак, кара урманнарда.*
*Бер... сулкылдау килә... узганнардан.*

*2006*

## ТАТАР

Башын куйган Идел мендәренә,
Күкрәгендә — Урал кыясы.
Буен сузган Кояш чыгышына —
Бу кыйтганың асыл Хуҗасы.

* * *

«Татар бугазы» диләр дә…
Татарның ул аяк очы бугай ла.
Сахалинны материктан
Этеп куйган, уңайлап…

## ЧАГЫШТЫРУ КИЛЕР БЕР КӨН

Тартария, Татар Ия…
Ничә тапкыр җуйган инде
Тәхет-бәхет алмасын.

Инде җирсез-сусыз калып,
Халык гидай булмасын.

Шаһ Гали гали булган шул!
Дип әйтергә язмасын.

*2004*

* * *

И лә, и дә, и генә шул,
И дә торган ил генә.

Ни бит, ни дип, ни дисәң дә,
Туган ил шул бер генә.

*2004*

## ГАСЫР ЫЗАНЫН ЧЫККАЧ

Зынҗырлы заман зарыннан
Колаклар түнгән иде.
Яңа заман күлмәге дә
Зардан тегелгән инде.

Югыйсә гел көтә безне
Ал чәчәк тә гөл чәчәк.
Һаман алга чигенә шул
Кысыр ялган — киләчәк.

*2003*

## АКСИОМА

Баш биргәнгә шундый инде
Кырыс тормыш уены:
Җегәрлегә ияр була
Җебегәннең муены.

* * *

Эш атының тояклары
Буразнадамы юкара,
Өресе юка милләтнең
Эресе сабан-сукада.

## ШӘФӘКЪ ВАКЫТЫ

Елан кабыгын сала.
Адәм кылган эшләр өчен
Оялып шәфәкъ кызара.

Күктә — Иблис, җирдә гөнаһ
Кул бирешә үзара.

## КАРА СӨРМӘ

Каркылдады карга.
Кара сөрмә сызылып калды
Күкнең аяз күңеленә.

Үзең кылган гөнаһка да
Күнегелә, күнегелә...



## ҖЫЛАМАС ӨЧЕН

Елларны чишенеп ташла да,
Яшел чирәмгә манылып,
Ауный-ауный көл әйдә!

Көлеп чыныккан күңелгә
Йә, уз, сагыш, кил әйдә!

## УЙСЫЗ ГАВАМ УЕ

— Имсез илгә тиран кирәк!
Ә сәбәп бит тирәндәрәк…

## СТАЛИН

«Герцеговина Флор» көйрәп торган
Челеменнән төтен бөркелде.
Һәм күмелде Себер томанына
Түбән-түбән халык төркеме.

## ЕРМАК

Себер изүен ул ачкандыр,
Юлбасарга һәйкәл куйгач,
Илдән иман качкандыр.

## ХАЛЫК УРМАНЫННАН БАРАМ

Бер сагаеп, бер сискәнеп,
Бер сокланып, ерып барам
Урман халкын.

Адашмаска, бер каһәрләп,
Бер кадерләп яратмаска
Бармы хакым?!

## АУРОПАГА СӘЯХӘТ

Төлке илләр арасында
Люксембург — нәни чебеш.
Иминлеген унбер солдат саклау тиеш.

## СТОКГОЛЬМ

Мин дә король сараенда.
Камыллы кырны тансыклап
Кызды аяк табаны.

Корольләргә сары алтын,
Безгә — арыш саламы.

## СИННӘН БАШЛАНГАН ДӨНЬЯ СИНЕҢ БЕЛӘН БЕТӘР

Ни хәлләрдә, Шәрык-Аксакалым,
Боекмале син алай!
Үз башына шаша Америка –
Елыйсы килгән малай.

* * *

Өрмә Кавказ тауларына!
Кайтавазың тау кашыннан
Убылыр үз башыңа.

## ЕЛЛАР УЗГАЧ

Гвадалквивир күпереннән
Суга акча ташладым.
Көмеш түгел дип, балыклар
Җыергандыр кашларын.

Еллар аша үзем хәзер
Көмешләнә башладым.
Чакырма, испан кояшы!
Гвадалквивир дулкынына
Йә үземне ташлармын.

*2004*



## ЯРЫЙ ӘЛЕ

Теләмичә китте кары да,
Сөендерми быел язы да.

Сәер уйлар килә башыма.
Орынган күк кабер ташына...

Кояш төшмәс кебек күңелгә.
Сыкрап эри бозлы күләгә.

Ярый әле бүтән кыйтгаларда
Җанны тарап исәр җилләр бар.
Безгә насыйп түгел ераклыкта
Кеше яшәр өчен илләр бар.

## БАР ИДЕ БИТ

Арыдым ла... Уйлар хәтта черем итә,
Кырынаеп күңел мендәренә.
Илләр иягенә йодрык терәп,
Менеп биек дөнья мөнбәренә
Нотык сөйләр чаклар бар иде бит!
Их, шул чакта күрмәдегез генә...

Хәзер инде кәгазь көймә йөздерерлек
Хис диңгезем калды тездән генә.

## ВАКЫТ АГЫШЫ

Уклы күзләр,
Утлы кузлар,
Сутлы тузлар.

Сүнгән эзләр,
Кемнәр эзләр?

Иң соңыннан —
Сүзләр... Сүзләр...

* * *

Саңгырау сүз яңгырамый,
Хәлсезләнеп, «һы»лана,
Яңгырашлы булыйм диеп,
«Сы»га килеп сылана.

## БАШКАЛА ТӨНЕ

Әйлән-бәйлән уйный карлар
Миллион тәрәз төбендә.
Күпме шагыйрь йокы чигә
Дәрте сүнгән өнендә.

* * *

Тукай яшен узган чакта
Сөрлекте шагыйрь аты.
Яшьнәде камчы офыкта —
Вакытның кулы каты.



## БЫЛБЫЛ ҖАНЫ

*Айлы шигърияте Тукайлы*
*Мөдәррис Әгъләмовка*

Ник шомлана күңел мәгарәсе,
Сизенәме тетрәү буласын.
Ничек инде шундый тыныч төндә,
Айны тешләп, бүре уласын?!

Салмак кына әнә карлар ява,
Күз күрмәгән җепкә тезелеп.
Гомер дисбесеннән алтмыш төймә
Сибеләме кинәт өзелеп?..

Меңтәрәзле Казан өсләреннән
Үтеп китә тәкъдир шәүләсе.
Яна шагыйрь — дөнья читлегендә
Кош кадәрле калган гәүдәсе...

Алтын бүре башын чөйгән халкы
Дәвер аръягында калса да,
Рухы аның Шагыйрь йөрәгендә —
Бүгенгегә килеп юл саба.

Шул халкым дип бәргәләнгән йөрәк
Соңгы тибешләрен саныймы;
Күкләр тынын сизгән былбыл җаны
Каурый канатларын сыныймы?

Салмак кына ап-ак карлар ява,
Мәңгелекнең шундый бер төне:
Туган телнең бәгыреннән, сыкрап,
Кубарыла асыл бөртеге.

Рәсүл үзе Шагыйрь маңгаена
Учын куйса, кем дә искәрмәс.
Таны соңлап, горур данын таны,
Бәхилләшмә, заман, исәнләш!

*2006*

## ХАК БӘЯГӘ ХАКЫ БАР

Буе — каләми.
Уе — галәми.
Сүзе — әләми.
Үзе — Әгъләми.

## БЕЗНЕҢ ХАКТА

*Татарның Гомәр Хәйямы*
*Туфан Миңнуллинга*

Беркөн килеп, каһкаһәләп көләр Вакыт:
— Боларныңмы бөек булу исәпләре!..
Туфан, уйнап, робагыйлар язган чорда
Йөргән күпме шагыйрь кисәкләре…

## УЛ

Йөрәк белән язар иде —
Йөрәге юк.

Бармак яный — куркытырга
Өрәге юк.

Милләт башын борыр иде —
Терәге юк.

Үз-үзенә кабер казый —
Күрәге юк.

Озак яшәр — күк иленә
Кирәге юк.

## ШӘҺИТ ТҮГЕЛЛӘР ШАҺИТ

Шигыренә яланаяк керә,
И кинәнә, рәхәт чигә, көлә,
Иңли-буйлый зәм-зәм күлләрен.

Дөньялыкка кайткач, үзен таныр,
Тагын кия Иблис күлмәген…

## КЫЛ УРТАДА

Үтте җәйнең яшел давыллары,
Юашланды җилләр, сәлдерәп.
Бу гасырның соңгы сентябре
Миләшләрдә янды, мөлдерәп.

Соңгы дигән сүздән җан сискәнә.
Кысылып ла килә дөньясы.
Вак-вак дулкын булып таркала да
Ярга бәрә вакыт дәрьясы.

Иделләрдә — күңел. Күңелләрдә — Идел.
Кыл уртада — гомер көймәсе.
Каршы ярда — яшел томанлыклар,
Бу ярда — чал чорлар көмеше.

*2000 — 2007*

## АКЫЛЛЫЛЫК БӘЛАСЕ

Ялкаулыкның ялын сыйпап ятам,
Кысыр нокта эзләп түшәмнән.
Хәтер чатларына кайтыр юлга
Юшкын-юшкын еллар түшәлгән.

Уйлыйсы да килми, уйныйсы да...
Шундый гадел мәле бу җанның.
Табыныр да, абыныр да идем —
Тәхетләре ауган дөньямның.

Кумирлардан күмер генә калган,
Хәрабәле хәтер бу ярлар.
Көндез шәм яндырып чын зат эзлә,
Исәр дигән мөһер сугарлар.

Кеше дигән җанвар кая бара,
Тәңре аннан өмет өздеме?
Мәхшәр туе. Түзмәс, кагыныр Җир,
Ычкыныр да сабыр тезгене.

Чү... Ник эшләтәм әле... Уй кибәген
Җилгәрергә дигән башымны.
Ник кузгатам күкрәгемне баскан
Ваемсызлык дигән ташымны.

Читтән шулай... Йә, кем, кылны урап,
Күңел упкынына төшәлгән?
Ялкаулыкның ялын сыйпап ятам,
Пәрәвез җеп яшьни түшәмдә...

*2000*

## МИН БОЛАЙ ИДЕММЕНИ

Манылды күңел күкләре
Шәфәкъләр кызылына.
Искитми генә әсәрәм
Дөньяның кызыгына.

Мин болай идеммени соң,
Мин болай идеммени?!
Сары яфраклы сабырлык
Көзенә килдеммени?..

Поездлар үтә ерактан,
Наратлар арасыннан
Бәрхет шау булып саркуы —
Юату көе сыман.

Китәсе килми, китәсе...
Каласы да килми шул.
Поездыңнан соңга калсаң,
Кадерең дә кими шул...

Наратлар да шәфәкъ ягын
Карыймы каерылып?
Аларга хасмы җан ашу
Урманнан аерылып?

Яшел чалмалы наратлар
Төштә түгел, өнендә
Ялгыз-ялгыз бер аварлар
Олыгаю төнендә.

Нигә соң болай уйланам,
Әллә көз сулышыннан.
Рельслар кереп югала
Урман борылышыннан;
Учтагы язмыш сызыгы
Кинәт өзелгән сыман...

*2006 – 2007*



## ГАҖИЗ СОРАУ

Үз-үземә читтән көлеп карыйм:
Каян килгән мондый сабырлык?
Юкка гына әйтмиләрдер әле:
— Теге чакларыңны сагындык...

Шаулы табыннарда тел сайратып,
Богемачыл гомер кичердем.
Хәмер әмеренә бирелми дә
Тормыш кызыгыннан исердем.

Хыянәтсез булдым тугры сүзгә,
Санга суктым дуслар өммәтен.
Корыч тавыш белән кайчак сүктем
Дөньялыкның шикле кыйммәтен...

Очынулар, ачынулар аша
Кабул булды күпме теләгем?
Кысыр туфракларга чәчмәдемме
Сәләт дигән Ходай бүләген,

Чәчкәнмендер. Сусыл шытымнарны
Бөгелеп лә кемнәр җыйгандыр.
(Каләм тотса, мәхлугы да безнең —
Үрә баскан кәрлә җиһангир...)

Чын остазлар инде бетә бара,
Юшкынлана телнең коесы.
Нәфеслеләр сүз имгәтә.
Җырда —
Көй аякка төшү тойгысы.

Күпләргә мин туры карый алмыйм;
Мәкер сүрүләре ертыла.
Керләнгәндер ишек тоткалары,
Андыйларның кермим йортына.

Менә тагын китеп барам әле
Сүз табасы кызган табыннан.
Кичерегез, ыспай бокалларым,
Кырын карап китсәм талымлап.

Җан авыша ялгызлыкка таба,
Тән-читлекнең сыный ныклыгын.
Миндә бара Күк һәм Җир тартышы.
Кагып иңнән дөнья ваклыгын
Тома ялгыз калгач, тәкъдиремә
Гаҗиз сорау бирә аламмы:
— Җаным белән Күккә ашаммы мин,
Тәнем белән Җирдә каламмы?..

## ӘЙ, КҮРӘЗӘЧЕ!

Кузгатма син рәмел ташларыңны,
Хыялларым күпме укталган.
Белми торыйм әле, белми торыйм,
Садагымда ничә ук калган...

## ЯМАНСУ

Үртәлеп карыйм суларга:
Агып бара гомерләр.
Чүгәли учак утлары,
Сыктап сүнә күмерләр.

Айгылдап кешни айгырлар,
Ярларын ташлый сулар.
Без киткәч тә дөнья шулай
Бик азга ямансулар.

*2005*

# *Ай — шагыйрьләрнең шәмаиле*





## СҮЗЛӘРДӘН — СӘЙЛӘННӘР

* * *

Аҗаган — күкрәвеннән тол калган кысыр яшен.

* * *

Чишмә — диңгез имиен эзләп чапкан сабый су.

* * *

Мәңгелек — яшәү уенының юаныч куены.

* * *

Түшәмдәге ботак эзләре — балачак хыялы яккан учак урыннары.

* * *

Син дә кайттыңмы таныш ызаннарга. Биштәр аскан бөкре шәүләң алабуталар хәтерен кытыклап бара.

* * *

Мунча иясе әллә кем түгел, ләүкә астында чуар түшен мимылдатып, арт аякларына чүмәшеп утырган сәйлән күзле бака булган икән лә!

* * *

Мең телдә шыбырдашкан үсемлек дөньясында салкын гөмбәзле гөмбәләр генә телсездер шикелле.

* * *

Тышаулы ат сикергәндә, җил оялып йөзен бора.

* * *

Күңелеңдәге ярсу үткелләрне йомшарту өчен гарәп мәкаме белән сафландырылган сүрә уку фарыздыр.

* * *

Балкып яна Тимер Казык йолдызы — галактиканың кендек туры ачылган.

* * *

Күңелнең дә күге җиде катлы. Иң тирәндә калган аяз гөмбәзлесе — балачак күге.

* * *

Шигъри хис өч яссылыкта бәргәләнә: үткәнне сыктап сагыну... бүгенгегә абынып кабыну... киләчәккә алданып табыну.

* * *

Юеш имән яфрагы яңагыма чәпәгәч, сискәнеп киттем. Җил котырткандыр. Кичә төнлә мин аның яңгырлы-елак гайбәтеннән качып, имән ышыгына кереп йомарланган идем.

* * *

Тәрәзәмнән җилфердәп керде дә күбәләк кәгаземә кунды. Өчпочмаклы галәм хаты. Канатына кояш нуры белән укалы сүзләр чигелгән.

* * *

Таңгы кояш кыерчыгын алдан күрер атка атланган ир-егет.

* * *

Дага бәхете — тояк белән җир арасында тукмалу.

* * *

Ат чыраена кизәнү атаңа кизәнүгә тиңдер.

* * *

Үткен кылыч җилдән дә кан чыгара.

* * *

Зиһен изүен шәрран ачма, уйсыз җилгә сыеныргa калсын аулак почмагың.

* * *

Гомер — йомгак. Алдан күпме уралган, шулкадәр сүтелә.

* * *

Тезләнгәннең рухы да тездән генә.

* * *

Турсаеп калыкса да, Ай нурлары үпкәчел түгел.

* * *

Далага табынып, тауларны иңсетмә, тауларга табынып, даланы кимсетмә.

* * *

Карга каркылдады. Күкнең аяз күңеленә кара сөрмә сызылып калды.

* * *

Дер селкетеп аю йөрмәгән урманның агачлары да басынкы була.

* * *

Туган якка кайткач... Әрем очы саен ак күбәләк! Малайчагым ак әләмнәр тезеп әсирлеккә төшә мәллә?!

* * *

Олыгайган тәрәзәдән карыйм: офык аръягында дегетле әремнән сыдыртып, җигүле ат артыннан яланаяклы дәрт чаба... Мин кычкырсам да, борылып карама, почык борынлы малай!

* * *

Һи малай! Бәллүр кыялары белән көтә сине Һималай.

* * *

Шундый ак төнбөек таҗлары, шундый ак! Күбәләк килеп кунса, ялан аяк эзе калырлык.

* * *

Шундый халәт: әрекмән яфрагына утырып, күлдә йөзәсе килә.

* * *

Таҗына чүгәләп, чәчәк елмаюын үбү — күбәләк бәхетедер.

* * *

Сискәнде җәй! Чалгы йөзен сыйпап узды кырыс ташлы янавыч.

* * *

Төшке чәй эчелгән. Учак күмере изрәгән. Чалгылар да чалкан төшкән. Покосларга кырынаеп, печәнчеләр җиләкле төш күрә.

* * *

Сандугач буласы килүдән кәккүкләр сакаулана.

* * *

Гәрәбә көз күкнең сүтелгән сүрүен торналар белән типчи.

* * *

Без утырткан чакта бу каеннар тездән генә иде. Бүген мин аларның тезеннән. Ә барыбер каеннар миңа «абый» диеп эндәшәләр шикелле.

* * *

Урман аланындагы түгәрәк күлгә кызыгып, төнге галәм күленнән маймыч йолдызлар сикерә.

* * *

Кәс-кәс басып, җитез кызый бара. Бөтерелмә итәгеннән, башы әйләнеп, чәчәкләр түгелеп кала.

* * *

Гүзәллекнең саф гөнаһы… узды таптап яшәвемнең көйле кагыйдәсен…

* * *

Нигә моңсуландык әле?.. Язмыш кыравы тиде мәллә син күрмәгән, мин күрмәгән абага чәчәгенә?

* * *

Үзеңә дигән бәхетне миңа теләдең; үземә дигән бәхетне сиңа теләдем. Еллар аша кайтыйк әле мәхәббәт ярына, алмашыйк әйдә бәхетләрне.

* * *

Уятма ярсу дөньяны, шакыма талгын күңелне — иңгә фәрештә кунган мәл!

* * *

Билен бөгеп килгән дә Җил, кичә дуамалланып давыллаган өчен, дер-дер калтырап, минем кичерүемне сорый.

* * *

Аклыдан киенгән халәт бу... Казанымның борынгы урамына савылып кына кар ява. Әллә нинди җанны кимсетми торган юаш моңсулык.

* * *

Куып җиттек, безне алмый киткән аргамаклар! Карлыккан шул картлык кыңгыравы...

* * *

Тиңсезне үлем дә тигезли алмый.

* * *

Ыргакның бөгелеп торуында хәтәр горурлык бар.

* * *

Сау рухлыга савылып көлү дә килешә.

* * *

Акыллыдан арып калсаң, тинтәк белән тигезләнерсең.

* * *

Әнкә карынында «Әллүки»не тыңлап яткан яралгыдан бөек татар тумас димә!

* * *

Төнге Күк астында йолдыз йөгертелгән уйлардан таңда төпчек фикерләр туа.

* * *

Җирдә онытма Күк барын, Күктә онытма Җир барын — шагыйрьгә шул хөкем карары.

* * *

Салам түбәле авылның кадерле хатирәсе: урам гөр килә. Асламчы-аламачы килгән. Арбасында хуш исле, аллы-гөлле әйберләр. Әй аламачы! Оялады учка сандугачы, һәр малайда — таш сыбызгы. Сызгыртмагыз: җилне уятасыз, дип кисәтә өлкәннәр. Ә безгә җилне уяту кирәк. Җилдә җилер чагыбыз лабаса!

* * *

Тустаганда — баллы кояш. Бал эчендә җансыз шөпшә. Нинди тәмле үлем.

* * *

Аһ, бу гүзәллек! Көзге, тәкатьсез калып, гүзәлнең кочагына авар шикелле.

* * *

Чишмәгә иелеп бер елады. Дулкынланды ерактагы диңгез.

* * *

Кәс-кәс басып, гүзәлкәйләр уза. Кысыр хыялларга, мөһер булып, «тояк» эзе кала йөрәкләрдә.

* * *

Иртәнге көзге каршында көзе җиткән ир сурәте; чәрдәкләнгән йөзенә сулышыннан томан төшә.

* * *

Ала карга бөеклеккә мөнәсәбәтен һәйкәл маңгаена сыек мөһер йөгертеп билгеле.

* * *

Кешелек тарихы — Ходайның биектән карап бер кинаяле елмаеп алу мизгеледер.

* * *

Җирнең бизәгеме без? Җирнең бизгәгеме без? Изаланган Җир, түземе төкәнеп дер селкенер дә кешелек дигән тузаннан кагыныр шикелле.

* * *

Тануны сорамый тормыш кануны.

## ШИГЪРИЯТ РУХЫ

Шагыйрьлек «җене» кагылу, хыялый алдану бәхете күпләргә бирелгән. Әмма һәр милләтнең күз карасыдай чын шагыйрьләре гасырдан гасырга бөртекләп кенә туадыр. Ул халык бәгыреннән янартаудай бәреп чыга да, билгеле бер көйгә салынган аң-зиһен галәмен җимереп, тирә-юньне күмеп китә. Бу гарасатлы көч тынгач кына, аның никадәр олылык иясе икәнен тора-тора аңлый барасың.

Үсендереп кенә үстереп булмый чын шагыйрьне.

Ни хикмәт, һәр каләм иясенә мәңгелеккә табыну нәфесе, беренче буласы килү зәхмәте кагылган.

Бу — бик табигый фал.

Илаһи сүзне егәрле алу осталыгына ирешкән җанның йолдыз җиленә өмет-хисләрен таратып алырга да дәхеле бардыр.

Аллаһы, шундый кысыр бәхет иңдереп, безне һич тә рәнҗетмәгән. Чөнки без — каләмле затлар, телне сугаручылар; сүзләрне куныкландырмыйча, алтынын — алтынга, мәрҗәнен мәрҗәнгә аерып, йокымсырарга ирек бирмичә, һәр күзәнәгенә тере сулыш өретеп, хәрәкәттә тотучы гадиләр.

Шагыйрьләр фәрештә булалмыйлар. Шуңа күрә алар да гөнаһтан хали түгел... Тарихка борылып карасаң да, бүгенгегә күз салсаң да, таныласы килү ләззәтенә үрелгәндә бер-берсен таптау һәм тапталу галәмәтләре — үзе бер кыйсса.

Елан кабыгын елга бер сала. Шагыйрь исә үлгәч кенә...

Ни генә кыланма: илбашы иңенә кунып сарай сандугачы булып сайра, хакими көч белән үзеңне мәҗбүри яраттыр, үз-үзеңә һәйкәл куй... Тагын язмышны әйләнеп узарга теләп әллә ниләр майтар!.. Беркөн килеп, шәхес йөзтүбән ава да, хакыйкать көзгесе каршында ялангач иҗатың торып кала. Гомереңбуе корган гөмбәз бер мизгелдә убылып төшә... Кәгазь көшелен җил җилгәрә, кибәк арасында ач бөртекләр генә шәйләнә.

Мирасыңа — мәрсия...

Чын шагыйрь, Иман биеклегеннән торып, дәверләр аръягына сүз йомгагын чөя алган икән, аны дәвер ызаннарында кузы калган учак көле арасыннан Вакыт кайтып күтәреп ала да мәңгелек бишегенә сала.

* * *

Сабакка үсми икән шул тарих сабагы. Үле мисал булып тамыр төпкелендә тарыгып кала. Акыл ияләре рәтендә каләм әһелләренең язмышын күздән кичерсәң, гыйбрәтле мисаллар бихисап. Тәхет, көч-куәт каршында горур кала белгәннәр бит элгәрләр!

Менә бер генә мисал: Шәрекъта Зөлкарнәйн дип йөртелгән Александр Македонскийны (безнең эрага кадәр 356—323 еллар) фарсыларга яу сәфәре алдыннан греклар үзләренең юлбашчысы итеп игълан итәләр. Җәмгыятьнең күз карасы саналган олуг шәхесләре җыелып җиһангирны котлыйлар. Арада бер акыл иясе, сүз остасы Диоген гына булмый. Моңа бик аптырап, яраннарын ияртеп атка менә дә җиһангир үзе философ янына китә. Коринф шәһәре читендә яшәгән Диоген исә бу вакытта кояшта кызынып, истирахәт чигеп ята икән. Капылт кына килеп төшкән шундый югары катлау ирләрен күргәч, Диоген торып утыра да, гаҗәпләнеп, Александрга төбәлә.

— Берәр үтенечең юкмы миңа? — ди Александр Македонский.

Диогенның шул мәлдәге җавабы кызык. Әмма бу ләззәтне азга гына сузыйк әле. Бүгенгеләр ничек, бүгенгеләр?..

Кайчан гына әле... Мәскәү Кремленең алтынга манылган залларында тәхет тоткан картлар каршында күндәм баш иеп бүләк алган әдипләрне күрә идек. Аларның куштанлык тәэсиреннән таралып киткән йөз-кыяфәтен күреп, сарказм, билдән чишенеп ташлап, көлә-көлә биергә мөмкин иде.

Кем тора синең каршыңда? Нинди юллар белән тәхет яулаган ул? Атка мендереп кара — менә аламы?! Кылыч тоттырып кара — тота аламы?!

Йөз меңләгән яугирне бертынга буйсындырырдай сүз әйттереп кара — әйтә аламы?!

Шагыйрь ике мәлдә генә тезләнергә хаклы: гыйбадәт кылганда һәм чишмәдән су эчкәндә...

Синда вөҗданлы иҗат юлы бирелгән! Иңендә гасырлар буена утлар-сулар кичеп рухи мирас калдырган мәшһүр сүз ияләре тора; алар рухын рәнҗетмә — кичермәсләр, гасыр катламнары аша «Акларммы?» дип мөлдерәп караган сәнгать ияләре кичермәсләр сүз иясенең иелүен.

Бүген иелгәнне киләчәк иелеп алмый. Тезләнгәннең рухы тездән кала.

Йә, каләм! Әйләнеп кайтыйк борынгы Элладага. Ярты дөньяны яуларга дип, Һиндстанга, ак таҗлы Һималай кыяларына күз аткан җиһангир Зөлкарнәйн «Берәр үтенечең бармы миңа?» дип сорау биргән иде бит әле...

— Әз генә кырыйгарак тартыл әле, кояшны каплыйсың! — ди Диоген.

Акыл иясенең бу сүзе күпме илләрне тояк астында калдырачак җиһангирга шулкадәр нык тәэсир итә ки, ул аның горурлыгына, бөек җанлы бу-

луына хәйран кала, кайтыр юлга чыккач, яраннарына болай ди:

— Әгәр мин Александр булмасам, һичшиксез, Диоген булыр идем...

«Кояшны каплыйсың...» Нинди тирән мәгънә. Тәвәккәллекнең, горурлыкның гыйбрәтле мисалы.

Әмма... сабакка үсми шул тарих сабагы, тамырда томаланып кала...

* * *

Шигърият ул йөрәк биеклегендә.

Әгәр инде күккә ашып, салкын дөньялар киңлегендә галәми җилләрдән таланып сүз кадерен җуя икән, яңадан йөрәк биеклегенә кайтып кунаклый алмый инде ул.

Шигърият ул йөрәк биеклегендә.

Әгәр инде кызыгып Җиргә сикерә икән, бөгелеп, бураздадан бәхет эзли-эзли канатларын имгәтсә, яңадан йөрәк биеклегенә менеп кунаклый алмый инде ул.

Җиргә якынайганда — Күкләр тынып, Күккә якынайганда Җир сулышын тойган шигърият былбылы гына йөрәк биеклегендә оя үрә ала.

Шушы ике яссылыкның урта ноктасын таба алу — шигъриятнең мөкатдәс хыялы; хыялы гына түгел — максаты; максаты гына түгел — илһамлы яшәү мәгънәсе...

Халыкның күңел Мәккәсендә түр мендәргә утыртылган солтанатлы шәхесләре күпме? Рухи гөмбәзебезне тотып торган асыл уллар йөз елга меңәү туса, сайлана-сайлана, мең елдан соң унау гына калырга мөмкин.

Үзе шигърияткә әверелә барган ерак заманнардан килгән баһадирлар, абруйлы акыл ияләре, руханилар, сүз пәйгамбәрләре... Аз дисәң, күп алар, күп дисәң, аз алар безнең халыкта, кадерли, барлый белү олылыгына ирешергә генә кирәк!

Төп тамырдан — татардан аерылып, бүтән милләт исеме алып яшәргә, үзбаш үсәргә омтылган кавемнәр бар. Бу кавемнәрне әйдәп баручы даирә төп тамырдан өзелгән милләтнең рухи үзәге имгәтелгәнен аңлап, түбән баскычтан башланган үсешнең кәрлә калачагын чамалап, ялган тарих җилкәсенә утыра да үткән дәверләрдән олы баба эзли башлый. Татар күкрәгендә ябалдашланган мираска кул сузарга да тайчынмый, чарасызлыктан үз кыйбласын эзләп бәргәләнә.

Бакый чорларга китмичә, бер гасырлык катламны гына ачып карыйк:

— үз вакытында Тукайны тудыра алмаган, ганимәтле сүз егәреннән мәхрүм калган кавемне ничек юатырга?

— үз вакытында Сәйдәшне тудыра алмаган, моңын раслап, гимн тантанасына ирешә алмаган кавемне ничек санларга?

— үз вакытында Урманчены тудыра алмаган, Күк астында яшәү рәвешеңне төсләрдә мәңгеләштерә алмаган кавемне ничек бәяләргә?!

Татарның милли рухы әнә шушы Тукайлар тавыннан яңа биеклекләргә сикереш ясый, ә инде уртак исемнән ваз кичкән бүтән кардәш кавемнәр исә үз түмгәген тау дип атап яңа киңлекләргә талпынып карый да... Нинди зур аерма! (Бу — сөенеч түгел, бердәм үсә алмау көенече...)

Төп тамырдан шифалы сут алган татар теленең шагыйранә бөеклеген бер «Идегәй» дастаны гына да бәхәссез раслап тора. Олы халыкларда шулай: дастаннарда сәргаскәр, илбашы, чәчән язмышлары җирдә барган аяусыз сугыш гөрелтеләре, кылыч-сөңге чыңнары аша сурәтләнә. Әмма сугыш күренешләрен мондый да гаҗәп тел үрнәгендә сурәтләгән әсәр дөньяда бер генәдер! Ул — «Идегәй» дастаны! Ул — ана телебезнең җәүһәри казанышы!

*«Шаң-шаң иткән шам кылыч — Идегәйнең кылычы. Төндә балкыр ут булган, көндә балкыр су булган, ут елдырым яшен таш — чын булаттан корычы, Аждаһадай сулаган ул кылычның сулышы».*

Искиткеч шигърилек, дәһшәтле күренешнең сүз энҗеләреннән чигелгән сәнгати сурәте! Кайсы тел, кайсы эпос, нинди сүз шарлавыгы моның белән ярыша ала?! Бу — халык күңеленнән убылган симфония.

Тел хасиятенә соклanудан күз яше чыгара торган искиткеч бөек поэма бу.

«Арыслан хәлдән тайса да, бер сарыклык көче бар...» дигән кебек, сүз төше мәрмәри мәкальгә әйләнгән хикмәтле юллары белән генә дә вакытны тез чүктерә ала. «Күктә Чулпан булудан суда чуртан булу артык». «Нинди юан булса да, ялгыз агач өй булмас: нинди ятыш булса да, ялгыз егет би булмас». «Ирнең күңеле ефәктәй — бер төйнәлсә чишелмәс». «Ком җыелып таш булмас, кол җыелып баш булмас!»

Аннары... мең еллар буена тына алмаган көрәш, туганга туган, ыруга ыру кылыч күтәреп, нинди гаярь халыкның үз кодрәтен үзе җуюның бәхетсез соңы хакында дөнья шигърияте көнләшеп баш иярлек юллар... Дастанның тетрәндергеч кыллары, матәмле сүзләрнең аһылдавы...

*«Җир китәр дә ни калыр? Җиреннән тайган ил калыр. Ил китәр дә ни калыр? Ил киткәндә йорт калыр, йорт китәр дә сөт калыр, ак күкрәктән сөт имгән сүзе татлы тел калыр. Тел китәр дә ни калыр? Язганнан язган хат калыр. Баш китәр дә ни калыр? Буында типкән кан калыр. Буыннан буын чабылса, ул чагында ни калыр? Йорт урынында яу калыр. Яу чапканда ни калыр? Ялгыз башы каңгырап, чүл далада тинтерәп, дуадактай хан калыр...»*

Җиһанга түбәсен терәткән җиде кыя, дәверләр учы булып җәелгән җиде дала шаһит: ярларын өч океан, җиде диңгез юган кыйтгаларга ия булып та, әкияттәге дию кебек җиде башка аерылган төрек дөньясының атлы дәверләр симфониясендә кисәтүле мәрсия булып яңгырый бу аккордлар...

Әрнүле бәгырь догасы.

* * *

Б у — с и н д ә м е, ш и г ъ р и я т,

ак кәгазь аланында каләм аягүрә басуга, яшәү суты өртелгән сүзләрнең, кысан шәкелгә буйсынып, хөр фикер күгенә сибелүе?!

* * *

Б у — с и н д ә м е, ш и г ъ р и я т,

сүз пәйгамбәре тарафыннан сайланган кандаш, аңдаш, моңдаш сүзләрнең илаһи бердәмлеге: думбра, кубыз, саз, гөслә кыллары чиртеп, тормыш-хәят хакында тәүлекләр буена кабатланмыйча җыру әйткән чәчәннәрнең тиңдәшсез тапкырлыгы.

* * *

Б у — с и н д ә м е, ш и г ъ р и я т,

аксакал Шәрекъның дастани олпатлыгы; илләр язмышын сөңге очына алып биетә алу аяусызлыгы; тәхет тоткан илханның кылыч сабыннан арыган кулына каләм алып, сүзгә сәҗдә кылу сәләте.

* * *

Б у — с и н д ә м е, ш и г ъ р и я т,

утлы-гарасатлы гасырлардан чит-читләре янып, көеп, таланып чыккан китапның үзәгендә сүз баганалары булып, исән калу бәхете.

* * *

Бу — синдәме, шигърият,
баш очында кылга эленгән кылыч торганда да иманга тугры калу тәвәккәллеге.

* * *

Бу — синдәме, шигърият,
Тубай агачына ялгыш кунган чәүкәне дә лачын кадере биреп тирбәтә белү юмартлыгы...

* * *

Бу — синдәме, шигърият,
еланнан елау көтмә, дигәндә дә, елдырымланып, еланны елата алу елдамлыгы.

* * *

Бу — синдәме, шигърият,
көчек сикертер көйгә кечек такмак язганны да каләм иясенә тиңләп үсендерү ихтирамы.

* * *

Бу — синдәме, шигърият,
халкыңның хасталы рухын, әрнетә-әрнетә уятып, асыл исеме биеклегенә күтәрә алу ихтыяры.

Бу — синдәме, шигърият,
ана теленә хыянәт иткәннәрне дә, өмет җиме калдырып, бәхилли белү олылыгы!

*Исемгә исем ялгана,*
*Уяна олы хәтер.*
*Хәтергә хәтәр сүз сайлап,*
*Киләчәк нәрсә әйтер?*



# *Марсель Галиевкә*

*Мөдәррис Әгъләмов*

## ЯШӘҮ ТАЛАНТЫ

Иң кодрәтле — Вакыт,
Ул үтемле сабак;
Кайчак аны үтерәбез
Минутларны санап.

...Кайтасыбызны белмибез
Канатыбыз канап;
Вакыт белән дус яшәү ул —
Үзенә бер талант.

*1999*

*Илдус Гыйләҗев*

## ӨЧ ТЕРӘҮ*

Бер үк елда туган малайлар без,
Бер үк яктан, бер үк төбәктән.
Гамәлләребез дә шундый охшаш —
Хис дулкыны кайный йөрәктә.

Чатыр тауга карап өч ягыннан,
Өч хыялый өскә үрләдек.
Шуңа микән җиңел яуландылар
Яшәешнең башка үрләре.

Хис кимесә, имеш, куәт кайта,
Өч каләмне тауга сөядек.
Туган якны Чатыр тавы белән
Горурланып һәрчак сөйләдек.

Өч терәүле җисем аумый, диләр.
Ул каләмнәр әле торамы?
Тау ишелер, аның берсенә дә
Кагылмагыз... миннән сорамый...

*1996*

* Бу «өчлек»тә Илдус Гыйләҗев, Нур Әхмәдиев, Марсель Галиев күздә тотыла.

## БАРЫП ҖИТӘРГӘ ЯЗСЫН

Узган еллар янган учак кебек,
Очкыннары оча яктырып.
Утырабыз бүген өчәүләшеп,
Дуслар җыеп, җырлап, чөкердәшеп,
Алтмыш учак көлен актарып.

Утлы күмерләре, һай, кайнар шул,
Тимерләрне хәтта эретә.
Бергә гомер иткән дусларны да,
Аяк чалып йөргән дошманны да
Бәяләргә тормыш өйрәтә.

Кашлар көйде, куллар... йөрәк пеште,
Аз булмады безгә каршылык.
Авырлыклар парга әйләнделәр,
Түземлеккә бездән өйрәнделәр,
Максатыбыз — бары яхшылык.

Учак арты учак сүнә бара,
Вакыт көтми: җитеш-җитешмә.
Җыйнаулашып тагын утырырбыз,
Бокалларга шәраб тутырырбыз,
Барып кына җитик җитмешкә!
...Барып җитеп булса җитмешкә...

*2006*

*Нур Әхмәдиев*

## СЕР БИРМӘГӘН БУЛЫП

Саубуллашкан саен бер үк сүзләр:
— Яңа килдең, инде китәсең?
Озатырга чыккач, сиздермичә,
Читкә карап яшең сөртәсең.

Кемнәргәдер биреп нигезеңне
Туган авылыңда — Балтачта —
Сагынмамдыр дигәнсеңдер, бәлки,
Уйладыңмы бүтән кайтмаска?

Кайткан чакта, дуадак каз кебек
Бәргәләнә җаның урамга.
Каз мамыгы булып төшәр идең
Үзең туып үскән курага —

Төшәлмисең.
Юкса Балтачыңда
Белмиләрме синең кемлекне?!
Баян абзый салган йорт та исән,
Тик үкенеч, түгел синеке!

Машинадан карап узасың да
Сер бирмәгән булып тормышта,
Китеп барасың син Азнакайга,
Йә Туйкәгә — дуска — Илдуска.

Яшәгәнең шәһре Казандыр да,
Җаның туган җирдә калгандыр.
Туган җирдән тамыр өзгәннәргә
Сагыну һәм сагыш язгандыр...

*1999*

*Ркаил Зәйдулла*

## ТАЛЛАР ГЫНА ҺАМАН

Ык өстеннән күләгәләр шуа,
Төнне йоткан уйчан әрәмә.
Кайсы кошның тавышы соң укшый?
Хәләл дә ул безгә, хәрәм дә...

Кылыч болгап җайдагатлар үтә,
Тояк тавышлары — дөп тә дөп...
Актарылып керә нинди заман? —
Ай каядыр китә кителеп.

Яулары да шул ук, аулары да...
Без битараф инде... Кем уяу?
Кайсы канатлыны ымсындырып
Чакыра шулай өскә Чатыр тау...

Тонык кына күкрәү ишетелә
Килер еллар безне бер аклар,
Шыпырт яла сыман яр астына
Егылалар кәрлә куаклар.

Күкрәү килә. Эчендәге кинә
Яшен ташы булып бер чыксын,
Кузгатсын ул гомер көзләрендә
Сүнгән өметләрнең җырчысын.

Бар да узар. Таллар гына һаман
Ык ярына ятып оерлар.
Без әйтергә теләгән сүз кебек
Суырылып чыгар суырлар.

*1996*

*Асия Минһаҗева*

## «УЕЛ»НЫ ҖЫРЛАГАНДА ЕЛАГАН ИР-ЕГЕТКӘ

Аяз көндә суккан яшен — синең яшең...
Белмәдем бит «Уел»дан да уеласыңны,
Ояласыңны күңелең матурлыгыннан!

Тетрәндерде мине җаныңның зурлыгы!
Горурлыгың зур синең,
Аңлыйм, чамасыз зур горурлыгың,
Тик шулай да юктыр каршы торырлыгың
Минем көчкә, минем хискә.

...Кайтмадым мин синең янга, килдем генә.
Мин дә горур санаган башымны идем менә.
Эзли-эзли адашканда сине таптым.
Кояшым юк, ләкин җаным сөенечле,
күңел яктым!
Кайта дип көт, вакытлыча тагын китсәм.
Кичер, беразга калдырсам, ялгыз итсәм,
Йөгереп кайтырмын барыбер, кабаланып,
сулуым кабып.
Яшәрмендер күңелеңә үкенечле утлар ягып...

*1981*

* * *

Миңа никтер
Йә үзеңнән өстен булып,
Йә үзеңнән мескен булып
Яраткансың сыман тоела.
Урталыкны тапмагансың кебек,
Шуңа дадыр
Ялгыз килгәнсең күк туеңа.
    Хәзер менә
    Яратуда тигезлекне эзләп,
    Ярдан ярга бәреләсеңдер дулкын булып.
Кайныйсың син, батырырга әзерсең син,
Бер гөнаһсыз, бер гаепсез
                    упкын булып...

Сиңа сагыш юрыйм киләчәккә,
Татлы газаплардан искәртергә,
Үзен-үзе саклап туеп беткән,
Арган бәгыреңне нечкәртергә
Тырышмыйм мин.
Шулай килеп чыга —
Өзелдерә көннең бер мизгеле!
Сызылып үтеп киткән мәхәббәттән
Калдырырга иде сиңа бер изгелек!..

*1981*

*Гәрәй Рәхим*

## ДОГАЛЫ ЕЛЛАР

*Шул исемдәге китабы уңаеннан*

Үткәннәргә кире кайтып булмый...
Шлагбаумнарда ул юллар.
Шулар аша безгә үрелеп карый
Догалы еллар.

Узганнарны уйлап җаннар сыкрый,
Вакыт — патша җирдә, без — коллар.
Кайтарыгыз мине яшьлегемә,
Догалы еллар!..

Әмма безгә гомер биргән өчен,
Биргән өчен онык, кыз, уллар —
Һәрбер нәсел саен рәхмәт сезгә,
Догалы еллар!

Алда тагын ниләр күрербез без,
Язмыш безне ничек боргалар?..
Күрәчәкләребез сезнең кулда,
Догалы еллар...

Кеше гомере бигрәк нәзберек шул:
«Кыймылдыймы йөрәк... кан... куллар?..»
Тып-тын гына агып ята гомер,
Кеше гомере — Догалы еллар...

*2007*

*Зиннур Хөснияр*

## РУХ

Күбәләкнең канатына Илаһ
Ука белән язган сүрәне
Укыгандай тылсымланып калам,
Каян таба энҗе сүзләрне?!

Сүз тоягын җилле уйната ул,
Сүзгә маһир җаннар тоемлар;
Каләм очларыннан күкрәп тама
Ул дигәнчә туган тойгылар.

Бизәк ясый каләм һәммә сүздән,
Сулый җөмлә, хисләр тулышкан.
Чатыр тавы, янә бер үсенеп,
Иярена Айны утырткан.

Галиләргә гади булу кирәк —
Төшеп килә Чатыр тавыннан.
Күкләр тәмен татып кайтып килә,
Рухи баеп, туган ягыннан.

Гади генә Гали үзе болай,
Милли рухның җаны, үзәге!
Белә микән шуны: туган телгә —
Ходайның ул сирәк бүләге!..

*2007*

*Рашат Низамиев*

## ЧАТЫР ТАУГА КҮТӘРЕЛҮ

*(Мөсәгыйт Хәбибуллин, Марсель Галиев, Илдус Гыйләҗев һәм мин 1995 елны Чатыр тау түбәсенә күтәрелгән идек.)*

Чыкмадык без мылтык тотып ауга,
Күтәрелдек бары Чатыр тауга.
Үзенекен тукый һаман Марсель:
— Иң матур як кайда?
Аз-на-кай-да!

Без торабыз аягүрә басып,
Манзаралар аста — шәрран ачык.
Урал таудан килгән биеклектә
Үз-үзеңнән булмый икән качып.

Вакландык дип юкка оялабыз,
Биеклеккә менгән кеше генә
Азатлыкның җилен, тәмен татыр,
Һәркайсыбыз, бәлки, Алып батыр?!

Күзләрендә Мөсәгыйт агайның
Дөрләп китә тарих очкыннары!..
Кубрат ханга тәмам охшап калган —
Кием белән корал бир син бары.

Илдус Гыйләҗевне күр син әнә,
Кунаклары өчен өтәләнә;
Гүя Сократ: авыл фәлсәфәсен
Сибеп кенә сала өстәленә.

Марсель — вәзир…
Сөйләп кенә тора,
Бер алдыңа төшә, биш артыңа.
Кай арада гына өлгерә ул
Төрләнергә шулай биш-алтыга?!

Ә мин нәрсә? Гап-гади бер кунак,
Тыңлаганым, сөйләгәнем — тыйнак.
Ә мин — сакый, җилгә атланам да
Аркадашларымны йөрим сыйлап.

Безгә нинди ямьнәр кирәк тагы —
Тургайларның өзеп сайрар чагы.
Чү, егетләр! Калкып чыкты дәррәү
Чатыр тауның соры байбаклары…

Серле сурәт!.. Гүя үзәнлектә
Балбал ташлар аягүрә баскан.
«Орхон язмалары истәме?..» дип,
Тарих текәп карый сыман астан.

Гасырларны ерып, бу үләннәр
Яуга чыккан — гүя вавилоннар…
Туфрак булып, йөгерек үлән булып
Һаман яши бугай бакый җаннар!..

*2002*

*Газинур Моратов*

## МОНОМАХ БҮРЕГЕ

Алтын Урда — татарның Атлантидасы.

*М.Галиев*

Алтын Урда!
Азмы алтыннарың
Әверелгән ятлар күркенә.
Бүркең булса, бүре баласын да
Салып йөртер идең бүркеңә.

Син курганнар кебек яланбаш шул
Ялган баш шул безнең чорга да.
Бүрегеңдә әнә каракошлар
Ике башлы бала чыгара...

*2001*

*Фәйрүзә Исмәгыйлева*

## СОКЛАНУ

Илаһының юмарт бүләге —
Чатыр тау тәхете бирелгән.
Бөеклекнең данын, ачысын
Тоемлау бәхете бирелгән.

«Догалы еллар»ы әйтерсең
Гомернең сиртмәле коесы —
Тамчылап-тамчылап эчте җан
Саекмас мәхәббәт тойгысын.

Син — иреклe җан. Буйсынмас җан!
Син — тау кошы, мәгърур киек син.
Купыклыгың белән кызыклы,
Гадилегең белән бөек син!

Бәһаләрләр сине яңача...
Еллар үтеп бераз тын алгач.
Мәңгелек сыйган бу җаныңны
Бер кыска гомер аңлый алмас.

*2005*

*Алсу Гайфуллина*

## КҮҢЕЛ МӘТӘЛЧЕК АТА

Күңел безгә буйсынмыйча,
Үзенчә яшәп ята:
Әле мәтәлчек ата,
Әле тәмәке тарта.
Акыл һәм күңел җепләре
Тоташмаган микәнни? —
Күңел кылган гөнаһларны
Акыл үзе битәрли.
Сөю-сөелү эшендә
Гаҗәеп үк каршылык:
Күңел эзли үз тиңеңне,
Акыл эзли — яхшыны.
Әллә, мин әйтәм, һәркемдә
Ике җан яши микән?
Бәлки, алар көн башлыйдыр
Бәхәскә кереп иртән?
Берсе ак, берсе карадыр,
Бүген җиңсә карасы,
Теләсәң-теләмәсәң дә,
Сиңа начар буласы.
Агы җиңгән көнне синең
Юлың гел уңып тора.
Кешеләр сиңа соклана:
«Бу бигрәк әйбәт бала».
Менә шулай. Марсель Гали
Әйтмәгәндер белмичә.
Мәтәлчек аткан күңелгә
Тәмәке дә килешә.

* * *

И, без идек! Күрсәң! —
Бер ай күрми йөрсәк
Якын кешеләрне,
Очрашкачтын, елап,
Матур авыр сулап,
Кочаклашып алып
Тора идек басып.

Менә гомер узды.
Бер якыным белән
Унбиш елдан гына
Очрашырга язды.
Еламадык, түздек,
Кочаклашмадык та.
Күңел генә сызды
Без очрашкан чакта.

Саумы, якын дустым,
Саумы, олы дустым.
Картайгансың. Чәчең
Аксыл, аксыл. Аксыл...
Син дә китмә инде
Бөтенләйгә җирдән.
Күпме югалтулар
Ята безнең эздә.

Сабырлана чаткы.
Син үзеңне таптың.
Ә мин һаман эзлим,
Тапмасымны белеп.
Ярый әле язды —
Күрештек бу язны.
Унбиш елга торды
Сөйләшү бер күреп.

*Тамара Ганиева*

## МАЛЕЕВКА ИСТӘЛЕГЕ

Арбамыймы ничек карасам да,
Карашымда әллә утлар юк?
Ташлаганмы мине сөйкемлелек,
Күркәмлелек юкмы шулай ук!

Килгәнбезме җиргә мәңгелеккә,
Тәңреләргә тимәс өлешме;
Кем гаепләр дисең, кем битәрләр,
Бушатты дип әдәп-керешне.

Сине талкышлаган бу тормышлар
Мине дисеңмени аяган?
Инде миндә ничә тән ярасы,
Күңелгенәм ничә канаган!

Усал булма алай, болай да бит
Кыргын кебек кыра явызлык;
Һич югында, берәр алданаек,
Мәдхияләр булсын язырлык.

Их, вакланган заманнары менә,
Дуамаллык китә ир-аттан.
«Син үзең бит егет!» — дигән белән
Җаннарымны булам юаткан.

*1990*

*Лиана Әмирханова*

## РӘХМӘТ СИҢА

Сыйракларың бигрәк нәзек,
Чикерткә, дип үртәдең.
Син чикерткә дигәнгәме
Сикерә-сикерә үскәнмен.

Нәзеклегем буй-сынымның
Нәфислеге иде бит.
Шагыйрь абый, хәзер мине
Үртәмисең әле ник?

Буем үсеп, сине узып
Киткәнгәме соң әллә?
Үртәсәм, авырга алыр,
Җиткән кыз, дисең мәллә?

Әллә хәзер, шагыйрь абый,
Картаеп киттең инде,
Нәзек сыйраклы кызчыкны
Әллә оныттың инде?

Сиңа охшарга тырышып,
Шигырь юллары тезәм.
Гимнастика остасы мин,
Күп илләр-җирләр гизәм.

Рәхмәт сиңа, чикерткә дип
Үртәгәннәрең өчен.
Рәхмәт сиңа, Шагыйрь абый,
Матур иҗатың өчен.

*1994*

## ШАЯРЫШЛАР

*Илдар Юзеев*

* * *

«Сезгә мин кирәк». Галиләр
Атна саен тумыйлар.
Картайганны көтеп тормыйм,
Хәзер язам мемуар.

* * *

Бик зур сорау борчый мине, Марсель,
Шуңа җавап биреп кит әле:
— Бөек булып яшәү кыен микән?
— Аңла,
нә-дан…
түзәм бит әле!

*Рөстәм Мингалим*

## ОЛУГ БӘЙРӘМ

— Баян улы Галиевкә
Илле тулган, — ди халык.
Олуг бәйрәм тарафыннан
Бу бит бераз нахаллык!
Әкренрәк, ашыкмыйча,
Соңрак килсә ни булган?!
Соңламый, Марсель, бәйрәмнәр!
Котлыйбыз сине, туган!
Яшә күреп бәйрәмнәрнең
Олысыннан олысын:
«Алтын тотка»ң,
«Апрель кызы»ң,
Җырларың юлдаш булсын!!!

*1996*

*Разил Вәлиев*

## ШӘП БИТ

Тыйнак булдык — күрмәделәр.
Усалландык — багалар.
Ышанмасаң, укып кара,
Шәп бит «Кар абагалар»!

*1978*

*Гарифҗан Мөхәммәтшин*

## ИКӘН...

Киштәләрдә калын китап —
«Рух»мы, «Рухнамә» микән?
Рухың булып, намәң бетсә,
Яшәү мең бәла икән.

*Роберт Миңнуллин*

## АҢАРДАН БУЛЫР

Марсель юмор язган, диләр,
Аңардан булыр, булыр.
Безгә дә кирәк бит инде
Көлдерми торган юмыр...

* * *

Күрсәгез иде Марсельнең
Кукраеп торганнарын!
Әйтерсең лә үзе язган
«Әнкәмнең догалары»н.

*Ләбиб Лерон*

## ПЕСИ ЧЫГА

Мин, песине уятмаска теләп,
шуып чыгам юрган астыннан.
Төне буе Нур Гайсинны укып,
уянылган соңлап барсыннан.

*М.Галиев*

Ни укырга икән тагын диеп
Уйлап йөргән идек көн буе, —
Песи белән икәү сөт эчтек тә
Шигырь укып яттык төн буе.

Актардык без калын журналларны,
Калдырмадык әти гәҗитен...
Китапларын йотып кына тордык
Нур Гайсин һәм Зәет Мәҗитнең!

Сәгать саен туктап сөт эчәбез,
Күзләр ала бераз хәл җыеп.
Укый-укый теткәләнеп бетте
Нәни китап — Марсель Галиев!

Төне буе укып чыктык шулай
Һәм йокладык соңлап барсыннан.
Иртән, мине уятмаска теләп,
Песи чыга юрган астыннан...

* * *

Баяныч!
Кайда безнең таяныч?
Баяны-ы-ыч…
Хәлләр безнең… аяны-ы-ыч…

* * *

Роман язарга уйлады —
Башлады да ташлады.
«Төчкерек мәзәкләр» язып,
Күпме кәгазь «ашады»!
Юкка чыккан партиянең
Тетмәсен тетте, тетә…
Халык синнән, МАРКСель туган,
Яңа «Капитал» көтә!



*Рөстәм Зәкуан*

## ЮЛЫН КҮРСӘТСӘЛӘР...

М.Гали «бөек» дигәч,
Бөек буласы килә.
Ләкин ничек булырга?
Әйтми ансын үзе дә.

Хуҗа булып карадым,
Нужа куып арыдым.
Сәүдә эшен башладым,
Баю юлын тапмадым.

Депутат булдым бүген,
Калада яшим үзем.
Халыкка хезмәт итү
Булуны сорый түзем.

Башка юлын тапмадым,
Шигырь яза башладым.
Бәлки, бөек булырмын,
М.Гали әйтсә юлын.

## ОНЫТМАГЫЗ!

Чатыр тауны «үзләштерде»
Нур Әхмәди, Ирек Бәдри,
Имештер лә, тауны тери
Илдус Гыйләҗ, Марсель Гали.

Чатыр тауның ян-ягын да
Онытмагыз сез, дусларым,
Тауга Үчәлле ягыннан
Иңен куйган без барын!

*2006*

*Галимҗан Гыйльманов*

## КИЧЕР, ПОЭЗИЯ!

Гел чарасыз калам карашыңнан,
Сәер уйлар килә кабаттан:
— Мин нигә соң монда?
Тәңре сине
Шундый төгәл итеп яраткан...

*М.Галиев. «Тәңре барда...»*

Сыра тәмләп йөреп
Соңарганмын,
Бик бәхетсез булдым бу яктан:
Ярaталмый калдым,
Тәңре сине
Үз иркәсе итеп яраткан!

Их!
Газазилдәй баш күтәрер идем!
Чәчрәп чыгар идем!..
Тыйдылар.
«Тәңре өлешенә кермә, кермә,
Ходай барда телең тый», — диләр.

Хыялымда юкса мең мәртәбә
Гыйсъян булып җиргә атылдым...
Ялварыплар миңа карама син,
Такташ булалмадым, акыллым!

Мин нигә соң сиңа?
Тәңре сине
Төгәл, камил итеп яраткан!
Кичер мине, кичер, Поэзия,
Бөек булу шундый арыткан...

*Фәһим Шәймәрданов*

## СИН ӘЙТЕРСЕҢ, БӘЛКИ...

Бездә — диңгез каны бар.
*М.Галиев*

Елга ул чак безгә диңгез иде,
Дулкыннары йөгерек, чоңгыллы.
Офыкларга таба йөзеп киттек,
Күпләр ярга кире борылды.

Без давылдан куркып сайда калдык,
Син, чукынмыш, оста йөзгәнсең,
Тирән судан безнең куркасыны
Алдан күреп, сизеп йөргәнсең.

Шул чакта ук инде мәгълүм булган
Йөзеп чыгачагың аръякка.
Еллар үтте...
Син танылган шагыйрь —
И, куясың инде сайрап та!

Бер-бер артлы китапларың чыга,
«Алтын тотка», «Апрель кызлары»
Алла бирсә, «Энҗе тотка»лы да
Шедеврлар язарсың әле.

Син әйтерсең, бәлки:
«Чама бел, — дип, —
Артык борчак сибеп җибәрдең».
Юк, арттырмыйм, байтак талантлардан
Бер Дизельгә артык егәрең.

...Ә без нәрсә... һаман сай елгада
Коенабыз — калдык комганга.
Синдә — диңгез каны. Оста йөзгәч,
Дулкыннарны ерып йөз алга!

*1996*

# ЭЧТӘЛЕК

Туган тел шифасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5

*«Каләм очында — галәм...»*

Туган тел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
Илһам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 14
Ышанам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 16
Галәми уй . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 18
Хәят . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
Утлы дәрт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 21
Уяну үкендермәгән төш . . . . . . . . . . . . . . . . . . 22
Ике күк арасында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 24
Сер ачкычы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 25
Яшәү фәне . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26
Вакыт-акула . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 28
Дөнья каршында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 29
Вакыт-ата черем итә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 30
Теләкле терәк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 30

*«Гасыр китабын актарсаң...»*

Тузан булып . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 33
Ә шулай да . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 34
Ташлар дәшми . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 35
Ут күлмәге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 36
Дала догасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 37
Төштә абыну . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 38
Эзләмәгез . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 39
Җиһангир . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 40
Шәрекъ биюе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 47
Йола . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 50
Атлы Болгар ядкәре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 52
Дала каны . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 53
Бәгырь өзгәләнгәндә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 55
Табарлар безнең эзләрне . . . . . . . . . . . . . . . . 57
Ходайга да бик күңелсез булыр . . . . . . . . . . . 59

*«Җырладым сине . Җырыңда...»*

Хәнҗәр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 63
Җе-җе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 64
Буранда шыткан гөл . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 65
Хәтер тавында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 66
Тәкъдир . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 67
Кар аттың тәрәзәмә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 68
Урманчы кызы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 69
Түгәрәк аланда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 70
Әй . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 71
Тамырында... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 72
Август төне . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 73

Яратып кисәтү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 74
Яшьлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 75
Хәтәр мизгел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 76
Бер... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 78
Мин ашыгам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 79
Язмыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 80
Кая соң?.. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 81
Ут алма син шәмдәлләргә . . . . . . . . . . . . . . . 82
Сакла, Ходай . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 84
Хәтер бурлагы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 86
Унсигездә язган хатың . . . . . . . . . . . . . . . . 87
Тезгенсез сораулар . . . . . . . . . . . . . . . . . . 88
Әйе, беләм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 89
Мәхәббәт балдагы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 90

*«Җәйнең яшел куенына керәм...»*

Бер адым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 93
Кояш капкасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 94
Биеклекнең изүе ачык . . . . . . . . . . . . . . . . . 96
Бер көнлек гомер . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 98
Әбиле йорт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 99
Шәһәрдә нәүмиз хәтер . . . . . . . . . . . . . . . . 100
Тургай биеклеге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 102
Җәяүле буран . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 104
Кабатланмас әкият . . . . . . . . . . . . . . . . . . 106
Борылыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 108
Торналар төшкәндә . . . . . . . . . . . . . . . . . . 109
Нәфес . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 110
Тургай шәүләсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 111
Бәхетнең малай чагы . . . . . . . . . . . . . . . . . 112
Көзге кошлар кәрваны . . . . . . . . . . . . . . . . 113
Мин көтүче булам, дигән идем . . . . . . . . . . . 114
Шагыйрь кергән урманга . . . . . . . . . . . . . . 116
Уйлы урман . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 117
Томанлы август таңы . . . . . . . . . . . . . . . . 118
Сыктау . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 119
Соңгы... нинди хәтәр сүз . . . . . . . . . . . . . . 120
Васыять . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 122

*«Ничек кайтмыйм ди сагынып...»*

Әрем исе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 125
Карлы Казан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 126
Татар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 127
Чагыштыру килер беркөн . . . . . . . . . . . . . . 128
«И лә, и дә, и генә шул...». . . . . . . . . . . . . . 129
Гасыр ызанын чыккач . . . . . . . . . . . . . . . . 130
Аксиома . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 131
Шәфәкъ вакыты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 132
Кара сөрмә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 133

Жыламас өчен . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 134
Уйсыз гавам уе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 134
Сталин . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 135
Ермак . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 135
Халык урманыннан барам . . . . . . . . . . . . . 136
Аурупага сәяхәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 137
Стокгольм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 137
Синнән башланган дөнья синең белән бетәр . . . . . . 138
Еллар узгач . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 139
Ярый әле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 140
Бар иде бит . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 141
Вакыт агышы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 142
Башкала төне . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 143
Былбыл җаны . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 144
Хак бәягә хакы бар . . . . . . . . . . . . . . . . 146
Безнең хакта . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 147
Ул . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 148
Шәһит түгелләр шаһит . . . . . . . . . . . . . . 149
Кыл уртада . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 150
Акыллылык бәласе . . . . . . . . . . . . . . . . 151
Мин болай идеммени . . . . . . . . . . . . . . . 152
Гаҗиз сорау . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 154
Әй, көрәзәче! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 156
Ямансу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 156

*«Ай — шагыйрьләрнең шәмаиле...»*

Сүзләрдән — сәйләннәр. . . . . . . . . . . . . . . 159
Шигърият рухы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 167

*Марсель Галиевкә (багышлаулар)*

Яшәү таланты *(Мөдәррис Әгъләмов)* . . . . . . . . . . . 177
Өч терәү *(Илдус Гыйләҗев)* . . . . . . . . . . . . . . . 178
Барып җитәргә язсын . . . . . . . . . . . . . . . . . 179
Сер бирмәгән булып *(Нур Әхмәдиев)* . . . . . . . . . . 180
Таллар гына һаман *(Ркаил Зәйдулла)* . . . . . . . . . . 181
«Ул»ны җырлаганда елаган ир-егеткә *(Асия Минһаҗева)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 182
«Миңа никтер...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 183
Догалы еллар *(Гәрәй Рәхим)* . . . . . . . . . . . . . 184
Рух *(Зиннур Хөснияр)* . . . . . . . . . . . . . . . . 185
Чатыр тауга күтәрелү *(Рашат Низамиев)* . . . . . . . 186
Мономах бүреге *(Газинур Моратов)* . . . . . . . . . . 188
Соклану *(Фәйрүзә Исмәгыйлева)* . . . . . . . . . . . . 189
Күңел мәтәлчек ата *(Алсу Гайфуллина)* . . . . . . . . 190
«И, без идек!..» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 191
Малеевка истәлеге *(Тамара Ганиева)* . . . . . . . . . 192
Рәхмәт сиңа *(Лиана Әмирханова)* . . . . . . . . . . . 193

*Шаярышлар*

«Сезгә мин кирәк» *(Илдар Юзеев)* . . . . . . . . . . . 194

«Бик зур сорау борчый мине, Марсель...» *(Илдар Юзеев)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 194
Олуг бәйрәм *(Рөстәм Мингалим)* . . . . . . . . . 195
Шәп бит *(Разил Вәлиев)* . . . . . . . . . . . . . . 196
Икән... *(Гарифҗан Мөхәммәтшин)* . . . . . . . . . . 197
Аңардан булыр *(Роберт Миңнуллин)* . . . . . . . . . 198
Песи чыга *(Ләбиб Лерон)* . . . . . . . . . . . . . . 199
«Баяныч...» *(Ләбиб Лерон)* . . . . . . . . . . . . . 200
«Роман язарга уйлады...» *(Ләбиб Лерон)* . . . . . . . . . 200
Юлын күрсәтсәләр... *(Рөстәм Зәкуан)* . . . . . . . . . . 201
Онытмагыз *(Рөстәм Зәкуан)* . . . . . . . . . . . . . 202
Кичер, поэзия! *(Галимҗан Гыйльманов)* . . . . . . . . . 203
Син әйтерсең, бәлки... *(Фәһим Шәймәрданов)* . . . . 204

ISBN 529801640-5

9 785298 016407

Литературно-художественное издание

**Галеев** Марсель Баянович

**ТЕНЬ ЖАВОРОНКА**

Әдәби-нәфис басма

**Галиев** Марсель Баян улы

**УЧЫМДА — ТУРГАЙ ШӘҮЛӘСЕ**

Мөхәррире *Р.Ә.Заһидуллина.* Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин.* Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Ф.Р.Гыйсмәтуллина.* Корректорлары *Г.М.Хәбибуллина, С.Н.Галимуллина.* Оригинал-макеттан басарга кул куелды 18.03.2008. Форматы $75\times90^{1}/_{32}$. Офсет кәгазе. «Peterburg» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 8,13. Шартлы буяу-оттиск 8,44. Нәшер-хисап табагы 4,88. Тиражы 2000 д. Заказ Т- 237. Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19. **http://tatkniga.ru** **e-mail: tki@tatkniga.ru** Оригинал-макет Jaһat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.